ЧЫГЫМЛЫ ЭШ

Такси йөртүчеләр нинди шартларда эшли һәм нидән канәгать түгел?

> 5

ТӨЙМӘСЕЗ БУЛМЫЙ

«ВТ» хәбәрчесе башкала даруханәләрендә йөреп кайтты

> 15

БЕРЕНЧЕ ГЕРОЙ

Казанның бер урамына исеме бирелсә дә, Гыйльфан Батыршин турында белүчеләр бик аз

> 16

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 53 (28826) | Җомга | 15 апрель | 2022 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan /t.me/vatantat

4604609 000131

vk.com

СУ КЕРМӘСЕН АРАГА

ТАТАРСТАНГА ЯЗ КӨЧЛЕ ТАШУ АЛЫП КИЛДЕ

«Кар шәһәрегездә генә юк ул». Район-авыл җирлекләрендә яшәүчеләрнең сүзе бу. Яздан бәхет басканга шулай ди алар. Язгы ташу белән көрәшкән мәлләре бит. Гадәттән тыш хәлләр министрлыгыннан әйтүләренчә, Татарстанда 200ләп торак пунктка су басу куркынычы яный. «112» телефон номерына көн саен суның язгы ярсуларыннан зыян күрүчеләрдән берничә дистә мөрәҗәгать кабул ителә. Язның бик үк күңелле булмаган мәшәкатьләрен халык ничек хәл итә?

> 6

Ишетми калмагыз

Быел «Үлемсез полк» акциясе гадәттәгечә – урамнарда узачак. Бу хакта «Россиянең үлемсез полкы» хәрәкәтенең үзәк штабы рәистәше, генерал-полковник Сергей Макаров белдергән. Ватанпәрвәрлек акциясе 2020 һәм 2021 елларда, коронавирус пандемиясе сәбәпле, онлайн форматта гына үткәрелгән иде. Оештыручылар узган елда, илдәге эпидемиологик хәлнең начар булуы сәбәпле, 24 июньгә тәгаенләнгән урам йөрешен уздырмаска карар кылды. Ә онлайн акциягә Халыкара космик станциясе дә кушылды.

Бүген Татарстанда беренче чиратта төзекләндерелергә тиешле ишегалларын һәм парк-скверларны сайлап алу буенча сораштыру башлана. Чара барлык 45 районда үткәреләчәк. Ишегаллары Президент Рөстәм Миңнехановның «Безнең ишегалды» программасы буенча яңартылачак. Аларның исемлеге белән dvor.tatar сайтында танышырга мөмкин. Ә инде парк-скверлар «Уңайлы шәһәр мохите булдыру» федераль проекты нигезендә төзекләндерелә. Боларның исемлеге park.tatar сайтына урнаштырылган. «Татарстан шәһәрләрен үстерү институты» фондының архитектура проектлары департаменты башлыгы Наилә Зиннәтуллина әйтүенчә, җәмәгать урыннары буенча барлыгы 204 парк-сквер һ.б. тавыш бирүгә чыгарылган. Һәр муниципаль берәмлектә 3тән алып 27гә кадәр объект яңартылачак.

Киләсе 2023 ел азагына кадәр барлык сабыйлар балалар бакчаларында урыннар белән тәэмин ителергә тиеш. Россия вице-премьеры Татьяна Голикова шулай дип белдергән. Билгеле булганча, 3 яшькә кадәргеләргә урыннар җитәрлек түгел әле. Голикова әйтүенчә, хәзерге вакытта балалар бакчаларын төзү буенча Татарстан, Чечня, Пермь крае, Белгород һәм Рязань өлкәләре алдынгы. Быел илдә 45 яңа балалар бакчасы (6,6 мең урынга) эшли башлаган. Тагын 257се (38,5 мең урынга) ел ахырында файдалануга тапшырылырга тиеш.

Татарстан этнотуризм өчен иң кулай төбәкләр рейтингында өченче урынга чыккан. Бу хакта «РИА Новости» Tvil.ru сервисының тикшеренү нәтиҗәләренә таянып яза. Туристларның 12 проценты Казан, Алабуга, Болгар кебек шәһәрләрдә булып китү теләген белдергән. Бу җәһәттән беренчелекне Алтай крае (42 процент) алган. Туристлар күчмә тормыш алып баручы себер халыкларының тирмәләре, тормыш-көнкүреше, ашау-эчүе, кием-салымы белән кызыксынуларын белдергән. Май бәйрәмнәрендә Алтай тавы итәген шау чәчәккә күмгән себер сазанагын (маральник) фотога төшереп кайтырга хыялланучылар да байтак икән. Дагыстан (14 процент) – икенче урында. Искитмәле табигать почмаклары – Сулак каньоны, Сарыком калкулыклары белән хозурланырга, тау халкының гореф-гадәтләре белән танышырга, Дербент урамнары буйлап үтәргә теләүчеләрнең бик күп булуы ачыкланган. Этнотуризм буенча иң популяр төбәкләр исемлегенә Хакасия, Тыва, Саха, Чуашстан да кергән.

Районнарда ни хәлләр?

Зәй

Районда быел да язгы кыр эшләрендә иң тырыш механизаторга автомобиль бүләк итәргә җыеналар. Бу хакта районның авыл хуҗалыгы идарәсе башлыгы Фәрхәт Камалиев җиткерде. Кыр батырына «Лада Гранта» машинасы тапшырырга ниятлиләр. Механизаторлар һәм авыл хуҗалыгының башка тармакларында эшләүчеләрне бүләкләү өчен 2 млн 600 мең сум акча тотарга җыеналар. Алары, гадәттәгечә, Сабантуйда халык алдында олылаячаклар.
(«Зәй-информ»)

Алабуга

Алабугада «Приют человека» дип аталган хәйрия проекты эшли башлады. Аның кысасында «Алабуга» хәйрия фонды, шәһәр-районның актив яшьләре, эшмәкәрләр мохтаҗ, йортсыз, катлаулы тормыш хәлендә калган кешеләрне кайнар ризык белән тәэмин итә. Татарстанда «Приют человека» проектын 2018 елда Социаль тернәкләндерү һәм адаптация үзәге башлап җибәрә. Хәзерге көндә Казанда шундый 6 пункт булдырылган. Андый урыннар Чаллыда, башка шәһәрләрдә дә бар. Алабуганың 4 микрорайонында урнашкан Әҗмәл мәчете инде бер елга якын мохтаҗларны ашата. Хәзерге көндә анда атнасына ике тапкыр 70–80 кешегә кайнар ризык өләшәләр.
(«Алабуга нуры»)

Түбән Кама

Язгы чакырылыш барышында районнан хәрби хезмәткә 200гә якын кешене чакыру һәм җибәрү планлаштырыла. Бу хакта районның хәрби комиссары Фәрид Миңгәрәев хәбәр итте. Хәрби комиссариатта запаста 5500дән артык граждан исәптә тора, шул исәптән 2022 елның гыйнвар – март айларында беренчел исәпкә куелган 1350гә якын кеше бар. Апрель – июль айларында медицина һәм чакырылыш комиссиясе аша 1000нән артык түбәнкамалы узарга тиеш.
(e-nkama.ru)

Чирмешән

Әмир авылында яшәүче, армиягә китү яше тулган егетләр сөлге җыйдылар. Узган ел авылда биш пар кавышкан. Барысы да читтә яшәсәләр дә, күңелләре белән туган авылларында алар. Шул өйләнешкән парлардан егетләр чигүле сөлге алдылар. Әмирдә сөлгене апрельнең нәкъ икенче шимбәсендә җыялар. Таш яуса да, бу дата үзгәрми. Армия яшендәге егетләр хушбуй исле чигүле кульяулык өмет итсә, колгадагы башка бүләкләрне киләсе Сабан туена калдыралар. Фаяз Нуретдинов, Фәнил Сафин, Ранис Җиһаншин, Әлфис Нургатин, Равил Нуретдинов – быел авылда иң почетлылар, килен сөлгеләре, яулык һәм чигүле кульяулыклар бәйләнгән шома колганы көн буе җиргә төшермәделәр диярлек. Киләсе елда аларны яшьрәкләр алыштырыр.
(«Безнең Чирмешән»)

ПРЕЗИДЕНТТАН КИҢӘШ

Һөнәрнең артыгы юк. Татарстан Президенты Иннополис Университеты студентлары белән очрашуда шундый киңәш бирде. «Акыллы шәһәр»гә Рөстәм Миңнеханов ВЭБ.РФ дәүләт үсеш корпорациясе рәисе Игорь Шувалов белән бергә барды.

tatarstan.ru

Россиянең иң дәрәҗәле IT-уку йортында бүген дөньяның 44 иленнән килгән 893 студент белем ала. Якын киләчәктә аларның санын ике тапкыр арттырмакчылар. Шуңа күрә «акыллы шәһәр»дә 1 мең урынга исәпләнгән тагын өч яңа торак корпусы төзергә җыеналар. Цифрлы икътисад тармагына белгечләр әзерләүче уку йортында 17 лаборатория белән 9 тикшерену үзәге эшли. Биредә инде алты ел дәвамында Ясалма интеллект институты да эшләп килә. Әлеге институт белгечләре тарафыннан 54 проект чынга ашырылган, 800дән артык фәнни мәкалә басылган.

Иннополис Университеты студентлары белән очрашуда Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов республиканың IT-тармакны үстерүгә зур игътибар бирүен, әлеге тармак «җимешләре»нең сәламәтлек саклау, сәнәгать кебек бик күп тармакларда кулланылуын, университетны тәмамлаган белгечләргә ихтыяҗ зур булуын искәртте. «Көндәшлеккә тагын да сәләтлерәк булу өчен, сезгә өстәмә белгечлек үзләштерергә кирәк. Шулчак сезгә булган ихтыяҗ да бермә-бер артачак», – дип киңәш бирде Рөстәм Миңнеханов.

Зур кунаклар алдында «Сколково» идарә фонды рәисе Игорь Дроздов белән «Иннополис» махсус икътисади зонасы генераль директоры Ренат Хәлимов үзара хезмәттәшлек турында килешү имзалады. «Бу килешү ике як өчен дә файдалы. Без үзебезнең резидентлар өчен проектлар һәм анда катнашучылар саны артуына өметләнәбез. «Иннополис» үз эшен башлаучылар, проектларга акча җәлеп итү өчен өстәмә ташлама һәм сервисларга ия булачак. Уртак тырышлыгыбыз ил күләмендәге барлык инновация оешмалары үсешенә файда китерәчәк», – дип белдерде Игорь Дроздов документ имзалаганнан соң.

Хөкүмәт хисап тотачак

Алтынчы чакырылыш Дәүләт Советының утыз беренче утырышы 21 апрельдә узачак. Парламент президиумы утырышында шундый карар кабул ителде. Депутатлар 25 мәсьәлә, шул исәптән 9 республика законы проекты һәм 11 федераль закон проекты буенча фикер алышырга җыена.

Татарстан башкарма хакимияте органының узган елдагы эшчәнлеге нәтиҗәләре турында хисап утырышның көн тәртибендә төп мәсьәлә булачак. Парламентка документны Президент Рөстәм Миңнеханов керткән. Дәүләт Советына ул 8 апрельдә алынып, барлык профильле комитетларда каралган.

– Тулаем алганда, Хөкүмәт эшчәнлеге комитетларда хупланды, депутатлар, катлаулы мәсьәләләрнең чишелешен табу өчен ярдәм итәргә әзер, – диде Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин. – Пандемия һәм санкцияләргә бәйле кыенлыкларга карамастан, 2021 елда республика зур уңышларга иреште. Төбәкнең тулай продукты үсеше 103 процентлар артып китте. Торак һәм юл төзелешендә, социаль өлкәдә дә күрсәткечләр әйбәт.

Парламент башлыгы әйткәнчә, кешеләрне борчыган мәсьәләләр дә бар. Болар – азык-төлек белән тәэмин итү, кайбер төр продуктларга бәяләр арту.

– Бу – бөтен дөнья, бөтен Россия күләмендә шулай. Хөкүмәт, беренче чиратта, кибет киштәләре бушап калмасын һәм бәяләр кемнәрнеңдер баеп калу теләгенә бәйле рәвештә генә үсмәсен өчен, мөмкин булган барлык чараларны күрә, – диде ул. – Бу катлаулы чорда безнең төп бурыч – дәүләт һәм муниципаль хакимият органнарының тырышлыгын бер йодрыкка берләштерү.

Тикшереләчәк мәсьәләләрнең мөһимлеген исәпкә алып, район һәм шәһәр башлыклары утырышта видеоконференц-элемтә аша катнаша алачак.

Депутатларга шулай ук мәдәният, сәламәтлек саклау, мәгариф, социаль хезмәт күрсәтү өлкәләренә караучы оешмаларның хезмәт күрсәтү сыйфатын бәяләү нәтиҗәләрен дә җиткерәчәкләр. Ул Дәүләт Советының Социаль сәясәт, Мәгариф, мәдәният, фән һәм милли мәсьәләләр комитетларында тикшерелгән.

Утырышта башка мәсьәләләр буенча да фикер алышу булачак.

Тынычлык хакына

Виртуаль киңлектә яшьләрне ничек сакларга? Татарстанда террорчылыкка каршы комиссия утырышында шул сорауга җавап эзләделәр. Мәгариф өлкәсендә психологик иминлек мәсьәләләренә багышланган чараны Президент Рөстәм Миңнеханов уздырды.

Президент соңгы өч елда республикада укучылар һәм студентлар арасында шау-шу тудырган берничә вакыйга булганын искә төшерде. Мондый хәлләр яшьләр психикасына тискәре йогынты ясалуы турында сөйли. Нишләргә? Яшьләр арасында һәм мәгариф мохитендә киеренкелекне киметү өчен, төрле проектлар тормышка ашырыла. Федераль, республика дәрәҗәсендәге уртак тырышлык бу хәлләрне төбенә төшеп өйрәнү һәм алга таба аларны булдырмау өчен чаралар әзерләү мөмкинлеге биргән.

Рөстәм Миңнеханов әйтүенчә, яшьләр сәясәтендә ведомствоара хезмәттәшлекне игътибар үзәгенә алырга һәм вузларда психологик хезмәтләрне үстерүне дәвам итәргә кирәк. Хәзерге вакытта тәрбия эшен оештыруда җитешсезлекләр бар. Шул ук вакытта укучылар белән эшләү өчен квалификацияле психологлар җитми, диде ул.

Утырышта билгеләп үтелгәнчә, психологларның бер өлешен цифрлы мохиткә күчерергә мөмкин. Чарада катнашучылар балигъ булмаганнарга һәм аларның ата-аналарына психологик ярдәм итү өчен цифрлы платформа булдыру мәсьәләсен карады. Шулай ук республиканың мәгариф мохитендәге иминлекне төрле яклап тикшерү буенча тәкъдимнәр әйтелде.

СЕЗНЕКЕННӘН КИМ ТҮГЕЛ

IT-ПАРКТА МӘГЪЛҮМАТНЫ САКЛАУ ЮЛЛАРЫН БАРЛАДЫЛАР

tatarstan.ru

Мәгълүмат – икенче нефть, диләр. Ә «нефть»не табу гына түгел, саклау да мөһим. Бигрәк тә хәзерге вазгыятьтә. IT-паркта Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле каршындагы Мәгълүматны саклау буенча координация советы утырышы узды. Аңлашылганча, сүз мәгълүмат һәм мәгълүмат технологияләре турында барды.

Әмәгълүматны күз карасыдай саклар көннәр җиткән икән инде. Украинадагы махсус хәрби операция башланганнан бирле, ил компанияләре даими рәвештә киберһөҗүмнәргә дучар. Бу хакта утырышта Татарстан Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин әйтте.

– Аена 350 меңләп мәгълүмати һөҗүм ясала. Шушы шартларда республика, ил, товар җитештерүчеләр мәнфәгатьләрен яклау бурычы тора. Без хәзер мәгълүматның читкә агуын булдырмау эше белән шөгыльләнергә мәҗбүр. Җирле җитештерүчеләрнең мәнфәгатьләрен кайгырту да мөһим. Киберһөҗүм аларга да ясала. Безгә карата кызыксыну зур, чөнки Идел буе федераль округы нефть чыгару, нефть эшкәртү, машина төзелеше, авиатөзелеш һәм башка мөһим тармаклар белән уңышлы шөгыльләнә, күпләрне бу борчый, – дип искәртте Татарстан парламенты башлыгы.

Вазгыять куйган таләпләргә җавап табарбыз, дип ышандыра Фәрит Мөхәммәтшин. Аның сүзләренчә, цифрлы киңлекне, аеруча яшьләрне тискәре мәгълүматтан саклау мәсьәләсе кискен тора.

– Ә андый мәгълүмат Россиянең һәр төбәгенә өере белән килә. Цифрлаштыруга бәйле сораулар, мәгълүмат саклау юнәлешендә беренче генә ел эшләмибез инде, – диде Фәрит Мөхәммәтшин.

Мәгълүматны саклау белән беррәттән аны саклауны тәэмин итүче кадрлар мәсьәләсе дә телгә алынды. «IT-тармак белгечләрен әзерләү мәсьәләсе актуаль, – диде парламент җитәкчесе. – һәр товар җитештерүче, көндәшлеккә сәләтле продукция чыгаручы зур предприятиеләр мәгълүмат югалудан саклый һәм киберһөҗүмгә җавап бирә алырлык системага ия булырга тиеш».

Россия Президентының Идел буе федераль округындагы вәкаләтле вәкиле урынбасары, Координация советы рәисе Игорь Паньшин Татарстанны цифрлы киңлектә бу җәһәттән башкарылган эшләре, уңышлары өчен мактады.

– Татарстан – күп юнәлешләр буенча Идел буе округында гына түгел, тулаем ил күләмендә дә алдынгы төбәк. Мәгълүмат саклауны оештыру эшендә республикадан өйрәнерлек нәрсәләр бар. Соңгы айда дөнья нык үзгәрде. Куркынычсызлык мәсьәләсе алгы рәткә чыга. Хакимият органнары һәм инфраструктура корылмаларын ышанычлы саклауны тәэмин итәргә кирәк, – диде ул.

Утырышка кадәр кунаклар мактаган цифрлы алгарышны күрергә мөмкин иде. Әйтик, Татарстанның Мәгълүмат технологияләре үзәге генераль директоры Денис Улесов кушымталарны киберһөҗүмнәрдән саклый торган челтәрара экранны (Web Application Firewall) тәкъдим итте. Моннан тыш видеоконференцияләр оештыру өчен «Skype», «Zoom» кушымталарына алмаш булырлык «IZUM» проекты белән таныштырды. Аны республикада узган Бәйсез Дәүләтләр Берлеге илләре уеннары вакытында сынап караганнар иде инде. Хәзер аны министрлыклар кулланып карарга җыена.

Күпчелек компьютерлар эшләгән Windows операцион системасына алмаш Россиядә шулай ук бар икән. «Astra Linux» компаниясе төркеменең маркетинг буенча директоры Александр Гутин сөйләвенчә, уңайлыгы белән генә түгел, куркынычсызлыгы белән дә күпкә алдынгы ул. Аларның клиентлары – дәүләт компанияләре һәм дәүләт эшенә турыдан-туры катнашы булган кешеләр. «Безнең продукцияне гади кеше дә куллана ала. Әлегә процентлар белән әйтеп булмаса да, безгә карата кызыксыну һәм ихтыяҗ артты», – дип сөйләде ул.

Татарча сөйләшәбез

Руфина ФӘТТАХОВА

«Ватаным Татарстан» газетасының 1 апрель санында Айдар Шәйхинның татар сүзләрен дөрес язу, сөйләмдә логика саклау, тәрҗемә мәсьәләләрен яктырткан язмасын укыгач, минем дә кайбер фикерләр белән уртаклашасым килде.

Урамда кар ява

Еш кына: «Урамда кар ява», «Урамда яңгыр ява», – дигәнне ишетергә туры килә. Әмма кар урамда гына түгел, ишегалдында да, бакчада да һ.б. җирләрдә дә ява бит. «Кар ява, яңгыр ява», – дип кенә әйтү дөресрәк булыр иде.

Әчкече ханым

«Ханым», «әфәнде» сүзләрен элегрәк чыккан китаплардан укып белә идек. Хәзер көндәлек тормышта да шактый еш куллана башладык. Әмма һәр очракта да дөрес кулланабызмы соң ул матур сүзләрне? «Татар теленең аңлатмалы сүзлеге»ндә: кияүгә чыккан хатын (гадәттә аның исеменә ялгап, хөрмәт белән әйтелә. Таныш булмаган хатын кешегә хөрмәтләп мөрәҗәгать итү сүзе буларак та кулланыла», – дип язылган. «Мәдәни җомга»ның «Кеше һәм закон» рубрикасын алып баручы автор кирәкле, зур эш башкара. Ләкин... тәртипсез, пычрак телле, сәрхуш хатыннар турында «ханым» дип язып, гомуми тәэсирне боза дип уйлыйм.

«Зыялы» сүзен дә урынлы-урынсыз куллану кайчакта кире тәэсир тудырырга мөмкин. Зыялының русчасы – интеллигент. Әрсез, мактанчык кеше үзе турында: «Мин зыялы», – дип әйтсә, әллә ничек уңайсыз булып китә. Гомумән, «интеллигент» төшенчәсе үзе дә тулысынча хәл ителмәгән кебек. «Зыялы» сүзен укымышлы, намуслы, югары культуралы кешегә карата гына куллану дөрес булыр кебек.

Искиткеч ямьсез

«Искиткеч» белән «коточкыч» сүзләрен бик үк урынлы кулланмау шактый танылган язучыларда да очрый. Искиткеч – гаҗәеп, сокландыргыч. Коточкыч – бик куркыныч; бик каты. Әгәр ямьсез икән инде, ул искиткеч тә түгел, коточкыч та түгел. Бик ямьсез, дияргә була. Кем яки нәрсә турында сүз баруга карап, ачыклык кертергә була.

Еш кына «әһәмият» белән «игътибар» сүзләрен буташтыру да очрый. «Әһәмият белән тыңла», «Әһәмият итмәсәк тырыш» кебек очракларда «игътибар» сүзен куллану тиешле.

Таң калу, шаккату. Болар икесе дә бер үк мәгънәне аңлатсалар да, бераз аерылалар. Таң калу – соклану, хәйран калу, матурлыкка, гүзәллеккә карата әйтелергә тиештер. Шаккату – ниндидер күренешкә нык сәерсенү, гаҗәпләнү.

БӘЙРӘМНӘР ШАШЛЫКСЫЗ УЗАЧАК

Узган ел республикада 26 урман янгыны теркәлгән. Шул исәптән, урман фонды җирләрендә 19 янгын чыккан. Табигатькә 6 миллион сумлык зыян килгән. Коры үлән, чүп-чар, каты көнкүреш калдыклары януга бәйле 2068 очрак теркәлгән.

Бу хакта Татарстанның гадәттән тыш хәлләрне кисәтү, бетерү һәм янгын куркынычсызлыгын тәэмин итү комиссиясе утырышында Премьер-министрның беренче урынбасары Рөстәм Нигъмәтуллин сөйләде.

– Узган ел янгынга каршы утырышны алты тапкыр үткәрдек. Анда янгынга каршы тору өчен карарлар чыгарылды. Кызганыч, аларның барысы да тулысынча үтәлмәгән, – ди Рөстәм Нигъмәтуллин. Ул утырышта катнашучыларга җиңнәрен сызганырга кушты.

Татарстанның урман хуҗалыгы министры Равил Кузюров исә, һәр район белән видеоэлемтә аша сөйләшүләр уздырдык инде, ди.

– Гадәттән тыш хәлләр килеп чыкса, без төрле яклап әзерләндек. Техника җитәрлек, янгын сүндерергә теләк белдерүче махсус төркемнәр җыелды. Урманнарны күктән дә күзәтәчәкбез. Тиешле оешмалар белән килешүләр төзелгән, – ди министр.

Аның сүзләренчә, республикада төрле типтагы 25 урман янгынын сүндерү станциясе, янгынга каршы кирәк-яраклар тупланган 14 урын бар.

Инде хәбәр иткәнчә, республикада 25 апрельдән 15 майга кадәр янгынга каршы махсус режим гамәлгә кертелә. Бу чорда янгын куркынычы булган урыннарда коры үлән һәм чүп-чар яндыру, ачык утта ризык әзерләү тулысынча тыела.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе җитәкчесе урынбасары Сергей Сергеев, узган ел нәкъ менә махсус режим кертелгән вакытта янгыннар күп булды, ди.

– Апрель – май айларында республикада 1889 янгын очрагы теркәлде. Алардан 37 миллион сумлык зыян килде. Ут 34 кешенең гомерен алып китте, 18 кеше тән җәрәхәте алды. Янгында 328 корылма, 8 техника, 50дән артык терлек янып әрәм булды. Ә бит шушы янгыннарның 1017 очрагы коры үләнгә һәм чүп-чарга ут кабу аркасында килеп чыкты, – ди ул.

Янгынга каршы махсус режим кертелгән вакытта штраф күләме дә икеләтә арта. Гади кешеләргә – 2 мең сумнан алып 4 мең сумга, вазыйфаи затларга – 15 мең сумнан 30 мең сумга, эшмәкәрләргә – 30 мең сумнан 40 мең сумга, юридик затларга 200 мең сумнан 400 мең сумга кадәр штраф түләргә туры киләчәк. Әгәр учактан киткән ялкын аркасында урманга ут каба икән, гаепле кешегә җинаять эше ачыла. «Урман үсентеләренә зыян салу яки юкка чыгару» дигән маддәгә нигезләнеп, аңа 200 меңнән алып 400 мең сумга кадәр штраф салырга яки 3 елга иректән мәхрүм итәргә дә мөмкиннәр.

Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгының Татарстан идарәсе җитәкчесе Рафис Хәбибуллин әйтүенчә, быел бакчада һәм табигатьтә шашлыктан баш тартырга туры киләчәк.

Әйтеп кенә бактым

Риман ГЫЙЛЕМХАНОВ

Антиреклама

Соңгы 20–30 ел эчендә татар эстрадасына яңадан-яңа җырчылар килде, эстрада сәхнәсендә «кул тыгарлык та» урын калмады. Җырчылар ишле булган саен, алар арасында көндәшлек тә артты. Көндәшлек дигәннәре кара көнчелеккә әйләнеп, бер-берсенә антиреклама да ясый башладылар. Мәсәлән, «фәлән җырчының тавышы юк, фонограммага җырламаса, аны җырчыга санап та булмый...» кебек сүзләр ишетелә башлады, кайберләренең исемнәре дә аталды.

Хәтерлим: шул елларны иң зур тиражлы газеталарның берсендә «Фәлән Фәләнов фонограммага җырламый» дип язып чыкканнар иде. «Фәлән Фәләнов»ның исемен әйтмим инде, ул – әйбәт җырчы, бүген дә исән-сау. Менә шул җырчы "фонограммага җырламый" дигән сүзләрне үзе өчен антиреклама дип кабул иткән дә, газетаның баш мөхәррире янына кереп: «Ник мине мыскыллап яздыгыз?» – дигән.

Баш мөхәррир, әлбәттә инде, аптырап калган. Сәхнә йолдызларының шактые компьютер аша көйләп, тавышларын камил дәрәҗәгә җиткереп азапланган бер заманда, әлеге газета «Фәлән Фәләнов фонограммага җырламый» дип язып чыкты бит! Каян килеп мыскыллау булсын инде бу?! Әмма җырчы моны башкача кабул иткән икән. «Менә минем турында «Фәлән Фәләнов акча урламаган» дисәләр, синдә иң элек нинди фикер туган булыр иде?» – дип, мөхәрриргә бәйләнгән. Тегесе ни әйтергә белми аптырап калган. Ә «Фәләнов» аның саен бәйләнә икән: «Ә-ә, дәшмисеңме? Димәк, мин дөрес сөйлим. Минем фамилия кергән җөмләдә акча урлау турында сүзләр язылган икән, кеше инде, әлбәттә, монда нидер бар, дип уйлаячак. Сезнең «фонограммага җырламый» дип язуыгыз да кешене шиккә сала».

Мөхәррир өстәл тартмасыннан бер ярты чыгара, бераз тотып куялар болар. Мөхәррир хәмер җырчыны бераз тынычландырмасмы дип өметләнә, үзен сыйлаган кешене сүгү, нечектер, уңайсыз бит инде ул. Әмма башына «арыслан сөте» йөгергәч, «Фәләнов» тагын да катырак кыза башлый. «Син мине аракы белән генә майлый алмассың. Сезнең «Фәләнов фонограммага җырламый» дип язуыгыз «фонограммага авыз ачып тора» дип аңлашыла», – ди.

Мөхәррир моны миңа көлә-көлә сөйләде. Икенче яртының да башына җиткән болар, әмма теге җырчы: «Мин сезне барыбер болай калдырмыйм», – дип чыгып киткән.

Бу хакта мин нидер язарга дип күптән уйлап йөрдем, әмма башка бер җүнле фикер килмәде. Ә бит әлеге «Фәләнов» үзенчә җыр сәнгатенең камиллеге өчен көрәшкән. Фонограммага авыз ачып торуны тамашачыны алдау, аңа хәләл булмаган, контрафакт тауар сату дип кабул иткән. Һәрхәлдә, шулайдыр дип уйлыйм. Юкса ул гомер буе «тере тавыш» белән җырламас иде, башкалардан да таләп итмәс иде. Бүген ихласлыкка болай да кытлык. Җыр сәнгате дә, сәнгать булудан туктап, шоу-бизнеска әйләнеп бара. Ә югары зәвык тәрбияләү, тамашачыга, Тукай әйтмешли, «күңел рәхәте илә» җырлар бүләк итү кайда?

Мин бөтен җырчыларны бер чыбыктан сөрергә җыенмыйм. Безнең менә дигән җырчыларыбыз бар, алар бик күп. Әмма чын җырчылар арасында җырлаучыларның да буталып йөрүен күңел кабул итеп бетерә алмый, дип кенә әйтмәкче идем. Язганнарымны антиреклама дип тә кабул итмәгез, җәме!

БЕТКӘ ҮЧ ИТЕП, ТУН ЯГУ

БАНАН СТРАТЕГИК КОРАЛГА ӘЙЛӘНДЕ

Сүзне Кытайдан алган хәбәрләрдән башлыйк әле. Без коронавирус пандемиясен онытып, Украинадагы хәлләргә бөтен игътибарны юнәлткән бер вакытта, чин илендә аеруча зур кырыслык белән ковидка каршы рәхимсез сугыш алып баралар. 25 миллион кеше яшәгән Шанхайдан соң 18 миллионлык Гуанчжоуны бикләп маташалар. Шанхайда исә хәлләр яман, диләр: кешеләр ачыга, дару таба алмый, өметсезлеккә бирелеп, күккә ашар йортлардан түбәнгә сикерүчеләр байтак дигән хәбәрләр алына. Кытай – ябык ил: мәгълүматның дөресме-юкмы икәнен белеп булмый.

Чиннарның хәлен чамалап була. 2020 елның язында үзебезне кыска гына вакытка өйләргә бикләгәч, ничек үрсәләнгән, ничек ачыргаланган идек, хәтерлисезме? Хәтерләсәгез, аңлагыз: Кытай чикләүләре безнекеннән күпкә хәтәррәк. Мондый чикләүләр сәламәтлеккә дә, икътисадка да һәм, гомумән, яшәешкә дә ковидка караганда зуррак зыян сала. «Шулай булгач, локдаун нәрсәгә кирәк соң?» дигән сорау тумый калмый. Без инде күптәннән язабыз: Кытай икътисады зур дефолт алдында тора. Акча басып, аны гел артка таба чигерәләр, әмма һәрбер чигенүнең чиге бар. Локдаун зур түнтәрелешне аклау өчен менә дигән сылтау бит инде. Гаеп бездә түгел, коронавируста, дип башларны әйләндерә, миләрне томалый аласың. Ул гына җитмәсә, кайдадыр хәрби конфликтлар оештырып була. Кытай коммунистларында прагматизм җитәрлек, алар учакны үз төбәкләреннән ераграк та яга ала. Тайваньны уен тузы итеп саклаган хәлдә, каршы як картасын кечерәк карталар белән басалар. Әйтик, хәрби операцияне Азиядә түгел, Европаның үзәгендә үткәрсәң. Европалыларның үз хәлләре – хәл, шуңа күрә алар да тагын бер кайнар учак ягылса, бер дә каршы түгел кебек. Әйтик, Сербия Косово белән бил алышырга җыена. Әлегә кыюлыгы гына җитеп бетми, чөнки 1990 нчы еллар ахырындагы НАТОның бомбага тотулары аларның гына түгел, минем дә исемдә. Сербларга кыюлыкны Кытай кулы белән өстәп була. Соңгы көннәрдә генә чиннар яшерен рәвештә Белградка иң яңа HQ-22 зенит-ракета комплекслары китерделәр...

Бу дөньяда бар нәрсә үзара бик тыгыз бәйләнгән. Домино кебек. Бер доминоны алдыңмы, барысы да ишелә. Бер доминоны өстәгәндә дә шулай була ул. Баланс югала да, чайкала башлый. Бүгенге дөнья икътисады шул хәлдә. Без үткән көздә үк Evergrande дигән Кытай төзелеш компаниясенең бурыч астында калып, түләр җай тапмавы хакында язган идек бит әле. Evergrande кризисы әле дә дәвам итә. Түнмәсен дип аны терләр инде, әмма артык зур гигант ул, терәп торучылардан зур көч таләп итә. Андый хәлдә компаниянең кәгазьләре кыйммәтен югалта. Кемнәр җиңел ысул белән баерга дип акцияләр алган – бөләләр. Компания тора, аннан алда спекулянтлар егыла. Бу вазгыятьнең «Боинг» самолетының 132 кешенең үлеменә китергән мәтәлчегенә ни катнашы була ала, мәсәлән? Имеш-мимеш хәбәрләр, China Easten авиакомпаниясенең очучысы очкыч бортында үз-үзен үтергән, диләр. Рәсми хакимиятләр моны расламый, тикшерүнең тәмамланмавын әйтәләр. Пилот исә бар акчасын Evergrande акцияләренә салган икән. Шуннан бар кешене үзе белән алып китүдән дә яхшырак җай тапмаган. Дөрес булса инде. Менә бит ниләр эшләтә фонд базарындагы кризис кешеләрне!


vk.com

Фонд базарында гына түгел, дәүләт әҗәтләре белән дә хәлләр катлаулана әле анда. Кече илләр дәүләт дефолтларына старт биреп маташа. Ливан үзенең дефолт хәлендә булуын игълан итеп бетермәде, Шри Ланка «кемнәргә бирәсем бар, барыгызны да кичерәм» дигән формуланы кулланды. Бөтен тышкы әҗәтләре буенча дефолт игълан итте. Ил хөкүмәте отставкага китте, президентны армия саклый, азык-төлек кибетләрен дә хәрбиләр ил лидерын саклаган кебек саклыйлар. Социаль челтәрләр тулысынча бикләнде. Шри Ланка дефолты, әлбәттә, дөньякүләм финанс цунамие кузгалта алмый, ил артык кечкенә. Ә менә Кытай түнсә, хәлләр булачак. Күк асты илендә вазгыять начараюның тышкы билгеләре күренә инде. Чин державасы соңгы көннәрдә сыекландырылган газ сатып алуны киметә. Без газга бәяләр югары торганга сөенәбез сөенүен, ә кыйммәтчелекнең төп сәбәпчесесе – Кытай. Үткән ел ул кирәгеннән артык газ сатып алып, саклагычларын шулкадәр тутырды: европалылар Азия гиганты белән килешсәләр, Россия газыннан бик җиңел баш тарта алырлар иде. Гомумән, планетада газ да, нефть тә, ташкүмер дә җитәрлек, хәтта кирәгеннән артык. Аларның кыйммәтчелеге – махсус тудырылган вазгыять ул. Бу хакта аерым бер язарбыз әле, Аллаһ теләсә.

Глобаль капитализмның төп сыйфаты – бертуктаусыз киңәюгә омтылу. Базар киңәйгәндә, кризис була алмый. Киңәюдән туктаса, дефолтлар залпы башлана. Санкцияләр кертеп, хәзерге вакытта базарларны махсус чикләләр. Хаос тудырырга тырышалар ни өчендер. Соңгы көннәрдә Чили һәм Аргентина Россиягә литий рудасын сатуны туктатты. Боливия әлегә сата. Ул да туктатса, Россиянең технологик ыргылышына өметләр киселә дигән сүз. Моны мин әйтмим, Федерация Советында сөйләшү булды, шунда хәбәр иттеләр. Литийны ил үзе чыгара башлар иде, инвестицияләр, технологик җиһазлар таләп ителә. Алар булганда да әле, бу бер көнлек кенә эш түгел, еллар кирәк. Ярый, хуш, Россиядән үч алдылар, ди. Литийны безгә экспортлаучы илләр нишли? Табышны каян алалар, экспорт чикләнгәч? Эшчеләр кая китә? Беткә үч итеп, тун ягуга охшамаганмы бу? Охшаган шул.

Литийны һәм башка стратегик товарларны чикләсеннәр дә ди. Ә Эквадор бананнары нәрсә? Океаннан Россиягә банан ташучы компанияләрнең санкцияләргә кушылуы һәм банк аша акча күчерү проблемалары Эквадордан банан экспортын туктатты. Болай да фәкыйрь булган ил фермерларын ярсытты бу хәл. Банан сатып алучы илләр исемлегендә Россия, Кытай һәм АКШтан калышып, өченче урында тора. Иде... Кем югалта күбрәк? Бездә бәяләр күтәрелә бананга, ул дефицитка да әйләнә. Тегеләрдә төшә һәм сатучылар бөләләр.

Мисалларны күп китерергә мөмкин. Бөтен дөньяда азык-төлеккә бәяләр күтәрелә. Россия инфляция күрсәткечләре буенча алгы сафта бара баруын. Әмма Төркия безне дә узып киткән. Төрек инфляциясе – 61 процент. Әнкара килеп туган вазгыятьне үз файдасына борып ята. Ел ахырына кадәр Россиягә кием-салым, аяк киемнәре, текстиль экспортын 2–3 тапкыр арттырырга җыена. Украинаның оборона комплексына эшләүче инженерларын да үзенә сыйдырды. Безнең олигархларны да. Инженерлар технологияләр алып килсә, олигархлар акча ташый. Икесе дә файда бит инде. Төркия җимерүгә түгел, төзүгә омтылган бердәнбер дәүләт итеп күрсәтә үзен.

Бәяләр күтәрелү һәлак итми ул кешеләрне, аларның төшүе үтерә. Америкада 1981 елдан соң бәяләр рекордлы күтәрелә дип сөенүчеләр ялгыша. 40 ел элек янкилар инфляциядән үлмәгән бит. Ул чор кризисын алар социалистик лагерь илләре хисабына базарларын киңәйтеп җиңделәр. Хәзер тарайталар. Бөтен аерма шунда. Һәлакәтне базарлар тараю китереп чыгарачак. Эшсезлек бөтен планетада артачак. Ашарга акча таба алмагач, кешеләрнең бер өлеше үзләрен China Easten авиакомпаниясенең очучысы кебек тотачак. Башкалары фетнәчеләр лагерена басачак. Менә шул фетнә булмасын өчен, яңа сугыш учаклары ягачаклар. Без шул хәлне бүген үк күзәтәбез инде.

Россиянең якын килачәктәге хәлен Путин фаразы белән бәяләтик. «Урта сроклы һәм ерак сроклы перспективада хәвеф артуы ихтимал», – диде ул. Вазгыятькә һәрвакытта да алсу күзлек аша караучы лидерның да бәясе шундый булгач, без ни дип әйтик?

Рәшит ФӘТХРАХМАНОВ

БИРҮЧЕГӘ – КҮП, АЛУЧЫГА – АЗ

ТАКСИ БАЗАРЫНДА ВАЗГЫЯТЬ НИНДИ?

Соңгы елларда таксига ихтыяҗ тагын да артты шикелле. Халык аны беренче чиратта тиз һәм уңайлы булуы өчен үз итә. Тик такси йөртүчеләрнең дә проблемалары җитәрлек булып чыкты. Кем әйтмешли, ашаган белми, тураган белә. Алар әледән-әле шәһәр урамнарына чыгып, забастовкалар оештыра. Чираттагысы узган атна башында Казанда да булды. Такси йөртүчеләр нинди шартларда эшли һәм нидән канәгать түгел? Без шул хакта белештек.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Бушка эшлибез»

Дүшәмбе көнне башкаланың берничә сәүдә үзәге тирәсендә такси йөртүчеләр җыелып, республика җитәкчелегенә үз тәкъдимнәрен җиткерде. Тагын утызлап автомобиль Җиңү проспекты һәм Ямашев урамы буенча, колоннага тезелеп, акрын тизлек белән хәрәкәт итте. Шул рәвешле алар «Яндекс» агрегаторыннан таксида йөрү тарифларын кабат карауны таләп итте.

Такси йөртүчеләр сүзләре буенча, әлеге агрегатор акча эшләргә комачаулык итә торган яңа таләпләр куя.

– Элек без 10 сәгать эчендә 4 мең сум акча эшли идек, хәзер ул акчаны алыр өчен 16 сәгать эшләргә кирәк. Акча эшләр өчен, машина йөртүче тизлеген арттырырга мәҗбүр була. Аварияләр дә шул сәбәпле килеп чыга, – ди алар.

Хәзерге вакытта бер километрның бәясе тариф буенча 9 сумны тәшкил итә. Такси йөртүчеләр сүзләре буенча, бензин, машина юу, техник карауны исәпкә алганда, километрның үзкыйммәтен дә капламый. Моннан тыш, алар агрегаторга хезмәт хакыннан комиссия түләргә тиеш. Шуңа күрә такси йөртүчеләр акча эшли алмауларын яки гаиләләренә яхшы хезмәт хакы алып кайтып бирер өчен 16шар сәгать эшләргә мәҗбүр булуларын җиткерде.

Забастовкага такси йөртүчеләр түгәл таләпләр белән чыккан: беренче чиратта алар таксида йөрүне «счетчик буенча» исәпләүне сорый. Такси йөртүчеләр фикеренчә, бу аларга да, пассажирлар өчен дә отышлы булыр иде.

– Әлеге система ничек эшли соң: кеше такси чакырганга 100 сум түли. Һәр километрга тагын 20 сум өстәлә. Бу безгә генә түгел, ә беренче чиратта халык өчен дә отышлы булачак. Чөнки хәзер алар иртәнге һәм кичке пик сәгатендә югары коэффициент белән өч-дүрт тапкыр артыграк түли, – ди такси йөртүче Алексей.

Моннан тыш, машина йөртүчеләр «Яндекс»ның үзенең һәм таксопаркның комиссия процентын киметүне сорый. Шулай ук, алар фикеренчә, төнге тариф 20 процентка кыйммәтрәк булырга тиеш.

«Яндекс»ның матбугат үзәге «Татар-информ»га биргән аңлатмасыннан билгеле булганча, 8 апрельдән такси чакыру бәясе һәм кайбер тарифлар арткан. Мәсәлән, әгәр Казанда 9 чакрым ераклыкка бару «Эконом»да уртача – 175, «Комфорт»та 214 сум булса, 8 апрельдән алар 186 һәм 219 сумга күтәрелгән. «Шунысын искәртәбез: тарифлар таксида йөрү бәяләрен күтәрү һәм автомобильләрне карап тоту өчен чыгымнар артуны өлешчә каплау өчен үзгәртелде. Шул ук вакытта без һаман да таксиның халык өчен уңайлы һәм бәяләрнең алар күтәрә торган булуын телибез. Тарифларның кинәт үсүе сорауны киметергә мөмкин – заказлар кимегәч, машина йөртүчеләрнең дә хезмәт хаклары азаячак», – дигәннәр «Яндекс»та.

Айга... 100 мең сум

Шул ук вакытта аларның фикеренә теләктәшлек күрсәтмәүчеләр дә бар. Радик Абдуллин төрле агрегаторларда 5–6 ел эшләгән. Бүген ул шул ук «Яндекс» агрегаторында хезмәт куя.

– Мин забастовкаларның мәгънәсен күрмим. Урамга чыгу гына вазгыятьне үзгәртмәс дип уйлыйм, – ди ул. – Алар, бәяләр арзан, дисә, пассажирлар киресенчә, хакларның югары булуыннан зарлана. Еш кына баш та тарталар. Шул сәбәпле соңгы айларда сорау да кимеде. Югыйсә пандемия вакытыннан бәяләр дә күтәрелмәде. Соңгы вакытта хәтта пик сәгатьләрендә дә коэффициентны күтәрми башладылар. Бары тик иртәнге якта гына югары бәя куела.

Чыгымнар күп, дисәләр дә, таксида акча эшләп була, дип саный Радик.

– Берничә тапкыр китеп, башка эшләрдә эшләп караган идем. Ләкин кабаттан шушында кайттым. Мин үз машинамда чыгам. Берничә ел элек арендага да алып эшләгән идем. Тәүлегенә 1600 сум түләгән чаклар да булды. Биш көн эшләп, ике көн ял итәм. Кызганыч, хәзер «атналык смена»ны яптылар. Бу машина йөртүчегә билгеле бер вакытка һәр заказдан 18,5 процентлы комиссияне түләтмәү мөмкинлеге бирә иде. Казанда бер тәүлеклек сменаны (12 сәгать) агрегатордан сатып алу 600 сум торса, атналык (7 тәүлеккә лимитсыз) – 3,6 мең сум. Мин исә «Эконом» тарифта көненә 1500–4000 сум эшлим. Аена күп дигәндә 30–40 мең сум акча алам. Мин трассага чыкмыйм. Берничә тапкыр гына Яшел Үзәнгә, «Тура» базарына һәм «Зөя» тау шуу комплексына барганым булды.

Шулай да, Радик әйтүенчә, запас частьларга бәяләр күтәрелү хәлне катлауландырган.

– Машинаны карау авырлашты, – ди ул. – Чыгымнарның барысын да уйласаң, сәгатьлек керем бик аз кала.

Җәүдәт Ибраев ике ел элек Үзбәкстаннан күченеп кайткан. Таксида шул вакыттан бирле эшли.

– Мин Казан эчендә бөтенләй йөрмим диярлек, чөнки ул безгә файдага түгел. Бары тик аэропортка гына барам. Алай эшләгәндә отышлырак чыга. Иң күбе 100 мең сум акча эшләгәнем булды. Ләкин андый айлар бик сирәк була. Гадәттә кулга уртача 30 мең сум тирәсе керә. Машинаны да әледән-әле карап, тәрбияләп торырга кирәк. Мин һәр 10 мең чакрым узган саен машинаның маен алыштырам. Әле менә моторын караткасы бар, тәгәрмәчләрне алыштырырга кирәк, техник карау вакыты да килеп җитте. Кыскасы, бу айда миңа автомобильгә ким дигәндә 100 мең сум акча кертергә кирәк. Әле бу бензинны санамаганда. Үз машинаң белән йөрү отышлы түгел. Арендага алып эшләсәң, яхшырак, дип уйлыйм. Көненә 1300 сумыңны түлисең дә тынычлап йоклыйсың, – ди ул.

Контроль җитми

Шул ук вакытта ЮХИДИ хезмәткәрләре такси машиналары катнашындагы аварияләрнең артуын ассызыклый. Узган айда гына булган шундый очрак күпләрне тетрәндерде. «Казан – Ульяновск» трассасында «Киа Рио» машинасындагы такси йөртүчесе каршы ял полосага чыгып, фурага килеп бәрелгәнлеген барлык матбугат чаралары язып чыкты. Куркыныч авариядә алынган җәрәхәтләрдән соң 30 яшьлек шофер да, аның янында утырып барган 59 яшьлек пассажир да урында ук һәлак булды.

Таксилар өлкәсендәге хокук белгече Елена Гращенкова фикеренчә, хәзерге агрегаторлар машина йөртүчеләрне тикшерә торган структураны юкка чыгарган. Шуңа күрә бүген теләсә кем такси йөртүче булып эшкә урнаша ала.

– Эшкә алу процессы бик җиңел: кушымтаны йөкләргә дә, заказлар кабул итә башлар өчен, программада теркәлергә генә кирәк. Машина арендага бирелә. Ә йөртүченең бурычы – акчаны ике кешегә (арендага бирүчегә һәм агрегаторга) бирү. Хәзер беркем дә машина йөртүченең хәле белән кызыксынмый. «Эш бирүче»не хәтта машина рулендә утыручының җинаять кылу-кылмавы, ярамаган матдәләр куллану-кулланмавы да борчымый, – ди ул.

Хокук белгеченең фикерен Россиянең автомобиль хуҗалары федерациясенең Татарстан буенча вәкиле Рамил Хәйруллин да куәтли. Такси йөртүчеләрне берләштерүче һәм аларның эшчәнлекләрен контрольгә алучы рәсми оешма булырга тиеш, дип саный ул.

– Бу такси йөртүчеләрнең забастовкага беренче тапкыр гына чыгулары түгел инде. Күп тапкыр кемгәдер нәрсәдер җиткерергә талпындылар. Ләкин анда аз кеше катнаша һәм аларның сүзе ниндидер көчкә ия түгел. Аларның төп проблемасы – рәсми оешмалары булмауда. Бу эшне күптән башкарырга кирәк иде инде. Шулай булган очракта, такси йөртүчеләр исеменнән агрегаторлар белән билгеле бер ведомство эш йөртер иде. Ә болай алар бервакытта да теләгән максатларына ирешә алмаячак, чөнки алар таркау, һәркайсы үзе өчен генә җаваплы. Берничә агрегатор киткәч, такси базары тулысынча «Яндекс» кулына гына калды. Бу да яхшыга түгел, – ди ул.

Куркынычсызлыкка килгәндә, белгеч фикеренчә, такси йөртүчеләр машиналарын заказлар күп булсын өчен куа. Әлеге проблеманы муниципаль шәһәр таксие оештырып хәл итеп булыр иде, дип саный ул.

– Таксида хезмәт күрсәтү өлкәсе хәтта Хезмәт кодексына да керми. Мин әле дә муниципаль шәһәр таксие булмавына гаҗәпләнәм, – ди ул. – Ни өчен хөкүмәт органнары үзләренең таксиен оештырмый? Ул шул ук җәмәгать транспорты кебек эшләр иде. Барысы да – машиналар да, йөртүчеләр дә контрольдә, рәсми булыр иде. Европаның барлык шәһәрләрендә дә бар андый таксилар. Ә бездә барысы да шәхси кулларга, агрегаторларга калды. Һәм нәтиҗәсен дә үзегез күрәсез. Алар бернигә дә җавап бирми, җаваплылык бөтенләй юк, бары тик керем генә кирәк. Такси йөртүчеләр исә, акча алып кайтыр өчен, берничә смена да эшләргә әзерләр. Тик, ул-бу була калса, алар япа-ялгыз кала. Шуңа күрә такси белән хезмәт күрсәтү базарында әлегә сораулар бик күп.

Зөһрә САДЫЙКОВА

< Ахыры. Башы 1 нче биттә

Сөендергән дә, көендергән дә ташу

Республикада язгы ташуның гөрләгән чоры. Куркыныч янаган участоклар контрольдә дип ышандыралар. Вазгыятьне көн-төн күзәтәләр. Су кайчан кими башлар – бу хакта сөйләргә иртәрәктер. Зур елгаларны әле боз кочагы җибәрергә теләми дә кебек.

Кайбыч районы бу арада аеруча игътибар үзәгендә. Журналистларның да, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы вәкилләренең дә. Бәрле белән янәшәдәге Зөя елгалары үз көчләрен күрсәтергә ярата бирәдә.

Борындык авылыннан Айгөл Хамматшина әйтүенчә, быел өйләренә су үтмәгән, әмма нәүрәпкә төшкән. «1979 елда гына өйгә су кергән безнең. «Ул язда чорма башында яшәдек», – дип сөйлиләр без – яшьләргә. 2000 нче еллар башында өй нигезенә чаклы су килгәне бар. Әмма зыян китерерлек итеп түгел. Без авылның читендә яшибез, иң соңгы урам ул. Ел саен урамны су буйлә инде, быел да күпер өстеннән шаулап акты. Елга авыл уртасыннан узгач, уртада «диңгез» җәелеп ята, балалар мәйданчыгы су астында калды, элекке балалар бакчасы бинасына кадәр су килде», – дип сөйләде ул.

Мәктәпкә дә су керде, дигән имеш-мимешләр ишеткәч, Борындык мәктәбе директоры Рания Хуҗина белән дә элемтәгә кердек. Әмма бу сүзләр хаклыкка туры килмәгән булып чыкты. Мәктәпкә бара торган юлны су булгән, әйләнеп йөрергә туры килә икән.

– Мәктәпкә беркайчан су кергәне юк, – диде директор. – Балалар мәктәпкә парк аша йөри, анда су юк. Кәҗә ермагы дигән урын бар, шулар су белән тулып, шуңа кар суы өстәлеп, арткы яктан әйләнеп, алгы якка килеп чыга ул безнең. Резин итек киеп йөрдек. Хәзер су кимеде инде. Берничә көн торды. Без яшәгән урамга су, гомумән, килми.

Яшел Үзән районының Татар Танае авылының су астында «йөзүе» турында хәбәрләр социаль челтәрләрдә тиз таралды. Шулай да, биредә яшәүче Рабига апа Баһаваева әйтүенчә, 2018 елгы көймә белән йөзәрлек ташу белән чагыштырганда быелгысы түзәрлек. Су озак торган торуын – 3 көн китмәгән. Башка елларда бер тәүлектә китеп бетә торган булган.

– Ел саен өйгә су керә иде. Быел бакча-ишегалды тирәсе белән генә чикләнде, юлны да өзмәде. Әмма авылның Гөбенә елгасы буенча сузылган дүрт урамында яшәүчеләргә зыян килде инде, мунчаларына да, өйләренә дә үтте, берәр метр су торды. Мичләре дә җимерелгән. Азмы-күпме иминиятләштерүдән булган ярдәмгә өметләнәләр, зыяны капланмасмы, диләр, – дип сөйләде ул. – 2018 елда бик көчле булган иде ул ташу. Быел Ышналы дигән елга килмәде безгә. Кырыйларын эттергәннәр дип беләм. Алдан чарасын да күрәләр кебек инде. Ничә ел дамба төзүләрен көтәбез. Булырга тиеш, дип ышандыралар.

Башка җирлекләрдәге вазгыятькә дә күзәтү ясадык.

Әйтик, **Аксубай** районындагы Кече Сәлчә елгасы тирәсен күптән түгел дрон ярдәмендә тикшергәннәр. Ул бу китерерлек су тыгылулар табылмаган. Гомумән, райондагы сулыкларда су дәрәҗәсе күрсәткечләре нормадан артмый, диләр. Аксубайда ул – 270, Кәкре Күлдә – 310, Сөнчәледә 440 сантиметрга кадәр күтәрелгән.

Су ташу дигәннәре элек **Нурлатның** Якты Күлендә көчле һәм куркыныч булган. 1970 нче еллардагы табигать көйсезләнүен әле дә хәтерлиләр. Соңгы елларда берничә дистә йортка су керү куркынычы янаган. Дамба түбән булганга, диләр. Хәзер ул тирәләрне күтәртеп, асфальт түшәп, мондый куркынычны киметкәннәр. Язгы ташуга көздән үк әзерләнәләр икән.

Апас та – игътибар үзәгендә. Зур Күккүз су басу куркынычы янаган авылларның берсе булып санала. Биредә үзара салым акчасына торба да салганнар. Авылның икенче башына да торба урнаштырганнар. Әмма су барыбер китеп бетми икән. Район башлыгы белән торба кую йә күпер салу кебек эшне башкару турында киңәшләшкәннәр.

Яңа Чишмәдә Шушма елгасы көйсезләнгән мәл. Ул да күпләрнең тормышын икегә аерган. Су шактый биек – 70 см күтәрелгән.

Казан, аннан бигрәк башкалага якын булган бистәләр дә яз айларында икенче Венециягә әверелә. Йортлар да, машиналар да, кешеләр дә чын мәгънәсендә берничә көн йөзеп йөрергә мәҗбүр.

Габишево бистәсендә яшәүче Диләрә Зарипова әйтүенчә, ярты бистә су астында калган. Моңа өстәп, бу тирәдә юл да юк. Монысы да халыкка шактый кыенлык тудыра.

Узган ел Татарстан территориясендәге язгы ташу чорында 20 муниципаль берәмлектә инфраструктура объектлары су астында калган, шул исәптән 3 йорт, 206 йорт яны территориясе, 540 бакча участогы, 9 күпер, 8 автомобиль юлы.

ЙОРТКА СУ ҮТҮ КУРКЫНЫЧЫ ЯНАСА, НИШЛӘРГӘ?

Су кимегәч, су астында булган азык-төлекне кулланмаска, су кергән коелардан эчмәскә, киселгән яисә асылынып торган электр чыбыкларына тимәскә, сак булырга.
Су киткәннән соң, йорт эченә кергәч, бүлмәләрне җилләтергә кирәк. Яктырту максатыннан ут кулланмаска, бары тик фонарь ише җайланмалардан гына файдаланырга. Электр чыганаклары белән сак булырга.

СУ КЕРМӘСЕН АРАГА

– Юлны үз көчебез белән салабыз диярлек: әле үзара салым акчасы кулланыла, әле күрше-күләннәр белән җыелышып, кирпеч, вак таш китертәбез. Бу салынган юлны алга таба зур йөк машиналары, йөк төягечләр йөреп, җимереп бетерә. Урамыбыз белән инде икенче мәртәбә җыелган күләвекләрне суыртып, урман ягына җибәрдек, – ди ул. – Бистәдә Узорный дигән тыкрык бар. Анда элек тә сазлы чокыр иде инде. Яңгыр һәм кар сулары шунда төшә. Ул җирләрдә элек урман кебек урын бар иде, кешеләр ял итәргә, этләр белән йөрергә шунда баргалады. Йорт төзүче оешма, шул җирне сатып алып, өйләр төзеп чыкты. Төзелеш вакытында ук су баса иде инде шул тирәне, бистәнең бөтен суы шунда ага бит. Урамнарны су баскан икенче язы инде бу. Урамга чыга алмау – бер хәл. Кешеләрнең чокырларына, септикларына су тула. Бу инде – кешеләр сусыз утыра дигән сүз. Иң гади табигый ихтыяҗларын да үтәп булмый – бәдрәфкә дә йөри алмыйлар, димәк! Саный китсәң... Септикларны чистартып торабыз инде, аңа кар суы белән тулырга берничә көн җитә. Насосның тик торганы юк, кыскасы.

Кемнән ярдәм көтәргә?

Табигый көчләр белән тарткалашканнан соң, зыян күләмен барлар чак җитә. Су басудан соң ниндидер матди ярдәмгә өмет итеп буламы?

Хокук белгече Ләйсән Халикова әйтүенчә, су басу, янгыннар – табигый бәла-каза санала, димәк, андый вазгыятьне гадәттән тыш хәлләр рәтенә кертәләр. Мондый хәлләр кешенең сәламәтлегенә һәм иминлегенә зыян сала торган һәлакәт булып санала. Аннан соңгы нәтиҗәләре дә дәүләт җаваплылыгында, димәк.

– Шуңа күрә матди ярдәм алу өчен, дәүләт оешмаларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Тик бу әле су басты да, сиңа акча бирделәр дигән сүз түгел. Чыннан да зыян килгән чакта гына ярдәм күрсәтелә. Ул төрле чыганаклардан килә ала. Беренчесе – төбәк бюджеты. Икенчесе – федераль. Зыянны иминият компанияләре дә кайтара. Монда инде кеше үз милкен алдан кайгыртып куярга тиеш, – дип аңлатты Ләйсән Халикова. – Көек бистәсен алыйк. Ни өчен аны су баса? Суны йота торган «ливневка»лар юк, диләр. Димәк, йортны төзүче (застройщик) моңа игътибар биреп бетермәгән. Аның исеменә шикаять язарга, судка мөрәҗәгать итәргә мөмкин. Кайбер очракта бу мәсьәләдә йорт төзүчеләр генә түгел, җирле хакимият тә җаваплы. Идарәче компанияләр җилкәсенә дә төшәргә мөмкин.

Бәла-каза кичергәннәр кая мөрәҗәгать итә ала соң? Ләйсән Халикова сүзләренчә, һәр кеше иң элек җирле хакимияткә барырга тиеш. «Гариза тапшырырга кирәк. Анда зыян күләме, дәрәҗәсе күрсәтелә, документлар китерелә, моңа өстәп, шәхеснең «прописка»сын йә шунда яшәвен исбатларга кирәк. Сәламәтлеккә зыян килгән икән, медицина белешмәсен дә алырга онытмаска. Милеккә зыян килә икән, фотосурәтләр булса яхшы», – дип аңлатты ул.

Күп очракта хакимият ярдәмнән баш тартырга да мөмкин икән. Бу очракта сәбәбе аңлатылган тулы җавап сорарга кирәк. Аннан исә шул җавап белән судка мөрәҗәгать итәргә.

Бәла-казалар вакытында нинди законнарга таянырга була? Хокук белгече шуларны да искә төшерде.

– Бу очракта берничә закон эшли. Бу – «Гадәттән тыш хәл турында» Россиянең федераль конституцион законы, «Халыкны техноген һәм табигый характердагы гадәттән тыш хәлдән саклау турында» федераль закон. Илнең иминлеген тәэмин итү буенча Президент Указы да шушында керә, – диде Ләйсән Халикова.

Ярның икенче ягы

Болганчык, пычрак, салкын су үсемлек һәм тереклек дөньясына да тәэсир итми калмыйдыр, мөгаен. **Казан федераль университетының табигатьне тергезү һәм су ресурсларыннан файдалану кафедрасы ассистенты, мөгаллим, эколог Наил Назаров** белән су басуның табигатькә йогынтысын барладык.

– Табигатьнең үзенә зыян китергәне юк, су басуның бар зыяны – кешегә генә, – ди белгеч. – Су басу – табигый процесс. Ел саен кабатлана торган күренеш ул. Су басудан соң килә торган уңай нәтиҗәләрне ассызыклап үтәргә кирәктер. Бердән, су ташыган урыннарда балыклар үрчи башлый. Кайбер балыклар үләннәр арасына уылдык чәчә. Аларның үрчү циклы тиз уза. Икенчедән, су басып киткән ялан-болыннарда туфрак яхшы күләмдә су белән тәэмин ителә. Озак вакытка дымлы булып кала. Су киткәч, дымлы туфракта үсемлекләр үсә башлый. Су ташуы вакытында туфрактагы, җирдәге төрле эрегән матдәләр бер урыннан икенчесенә күчерелә. Мондый күчеш башка урыннардагы туфракларны тукландыра, бу да – уңай күренеш. Су ташуы булмый икән – менә монысы начар. Көтелмәгән урында су басу башлана икән, бу инде – табигый-гидрологик цикл бозылган дигән сүз. Су ташу елдан-ел иртәрәк килә димәс идем. Табигатьтә барысы да үз җае белән бара.

Ел саен яз киләсен белеп, алдан хәстәрен дә күрәбез шикелле, әмма бары су басуга бәйле вазгыять кабатланып тора. Экологның моңа карата үз фикере.

– Бу инде күрелгән чараларның бик үк җиренә җиткереп эшләнмәвен әйтә. Метеорологик фаразлар да ясап куялар инде анысы. Әгәр елга ташый икән, бу, иң элек, кар күплеген аңлата. Тагын бер нәрсәгә игътибар итәргә кирәк. Туфракның каты тирәнлеге (глубина промерзания) бар. Ул аз, әйтик, 50–60 сантимер тирәсе икән, кар эрегән вакытта туфрактагы бозлы катлам да эри башлый. Эрегән су туфракка сеңә бара. Әгәр дә туфракның каты тирәнлеге зур, әйтик, метрдан да артык икән, бу очракта өстәге карлар эри бирә, ул туфракка сеңми, чөнки аста туң. Бу очракта ташу да көчле була. Шуңа күрә туфракның каты тирәнлегән дөрес итеп фаразлау мөһим. Моның өчен күзәтү эшләрен алып барырга кирәк. Ноябрьдән фаразлап куялар, кышкы күзәтүләр алып барылмаса, йә тиешле дәрәҗәдә эшләнмәсә, саннар төрлелеге килеп чыга да. Бер санга нигезләнеп фараз кылабыз, ә асылда башкача килеп чыга, – ди Наил Назаров.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

Теманың дәвамы 20 нче биттә >

22 апрельдә сәгать 10нан 12гә кадәр сезнең белән элемтәдә журналист **Динә ГЫЙЛАҖИЕВА** була. Сорауларыгызны, әйтер сүзләрегезне 222-09-75 номеры буенча җиткерергә мөмкин.

ХАЛЫК АВАЗЫ

Кредит каникулын ничек алырга?

Саклык банкыннан 1 млн 800 мең сум ипотека кредиты алган идем. Авыр хәлдә калдым. Каникул алырга телим. Шул эшне башкарып чыгарлык банк хезмәткәрен табарга булыша алмассызмы?

Суфия ШӘРӘФИЕВА. Казан

Редакциядән: укучыбызның әлеге мөрәҗәгатен Саклык банкының матбугат үзәгенә җиткердек. Тик, билгеле сәбәпләр аркасында, алар банк клиентының үзе белән генә сөйләшү мөмкин икәнен әйтте. Суфия ханымга әлеге сорау белән банк бүлекчәсенә мөрәҗәгать итәргә кирәк булачак. Матбугат үзәге аңлатуынча, кредит каникулы вакытында айлык түләү туктатылып торса да, банклар кредит өчен процентлар исәпләүне дәвам иттерәчәк. Каникул тәмамлангач, аларны түләргә туры киләчәк. Димәк, кредит буенча артык түләнгән сумма (переплата) да артачак дигән сүз. Кредит каникулы гамәлдә булган айлар хисабына кредитны түләү вакыты да озаячак.

Илнур Гарифуллин, юрист:
– Каникул алган кешенең, автомат рәвештә, кредит тарихы бозыла. Бу исә киләчәктә яңа кредит алырга туры килсә яки булган кредитны рефинансларга уйласаң, кыенлыклар килеп чыгарга мөмкин дигән сүз. Кредит каникулыннан файдаланган кеше ким дигәндә ярты ел дәвамында яңа кредит рәсмиләштерә алмаячак. Шуңа күрә аннан башка чара калмаганда гына файдаланырга кирәк. Дөнья хәлен белеп булмый дип кенә, тота-каба ябышырга кирәкми.

Юл акчасы алып буламы?

Пенсиягә чыкмаган очракта да, 55 яше тулган кешеләр юл акчасы алырга хокуклы икән, дип ишеткән идем. Бу сүз дөресме?

Илдар НӘҖМЕТДИНОВ

Россия Пенсия фондының Татарстан буенча бүлеге матбугат хезмәте:
– Пенсия алды яшендәге кешеләргә социаль ярдәм чаралары (транспортта йөрү өчен түләүгә ташламалар, субсидияләр һәм башкалар) һәм салым ташламалары бирелә, әмма ул барлык кешеләргә дә түгел. Ярдәм мөрәҗәгать итүченең кеременнән һәм милке булу-булмауга бәйле. Гомумән алганда, әлеге ташламаларны алыр өчен, нәкъ менә яшь мөһим. Алардан 60 яше тулган ир-атлар һәм 55 яшьтән башлап хатын-кызлар файдалана ала. Тик аларның картлык буенча иминият пенсиясенә алдан чыгарга дәгъва кылмаулары яки дәүләт хезмәткәре булмаулары кирәк. Шунысын да искәртәбез: әлеге категориядәге татарстанлыларга Пенсия фондыннан белешмә алырга кирәкми, чөнки фонд һәм ведомстволар арасында электрон хезмәттәшлек бар.

Пенсия алды яшендәге гражданнарга тиешле ташламалар турында тулырак мәгълүматны https://pfr.gov.ru/grazhdanam/zakon/ сайтына кереп табарга мөмкин.

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Хезмәт ветераны» исеме кемнәргә бирелә?

«Хезмәт ветераны» исеме кемнәргә бирелә? Һәм хезмәт ветераннарына нинди ташламалар каралган?

Илдус ГАЛИМОВ. Арча районы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге:
– Закон нигезендә, «Хезмәт ветераны» исеменә СССР яки Россия Федерациясе медальләре яисә орденнары, Россия Президентыннан грамота, Рәхмәт хаты алучылар, озак еллар эшләгән өчен ведомство бүләкләре алучылар дәгъва кыла ала. Әлеге исемне алыр өчен тагын бер шарт: хатын-кызларның ким дигәндә – 20, ир-атларның 25 ел эш стажы булу. Барлык кирәкле документларны җыеп, кеше теркәлү урыны буенча социаль яклау бүлегенә мөрәҗәгать итә ала.

Хезмәт ветераннарына торак-коммуналь хезмәтләр өчен 50 процент ташлама каралган, телефон өчен түләгәндә субсидия, юлда йөрү өчен айлык социаль түләү, протез куйдыру, чукраклыкны дәвалау бушлай. Дөрес, 2016 елның 1 гыйнварыннан кабул ителгән үзгәрешләр буенча, әлеге ташламалардан уртача айлык керем 20 мең сумнан ким булган очракта гына файдаланып була.

Алимент ник килми?

Балаларның әтисе 2016 елдан бирле алимент түли иде. Аңа узган ел ахырында эш урыныннан китеп торырга туры килде. Берничә айдан соң, быелның гыйнварында шул ук эшенә кире кайтты. Ләкин ни сәбәпледер, алименты күчми. Бу очракта мин кабат алимент ала башлар өчен ни эшли алам?

Гөлия ИБРАҺИМОВА. Казан

Суд приставлары федераль хезмәтенең Татарстан буенча идарәсе матбугат үзәге җитәкчесе Альбина Батыршина:
– Элеккеге ирегез рәсми төстә эшләсә, беренче эш итеп, аның хезмәт урынына барырга мөмкин. Моның өчен сез үзегез белән башкару кәгазен (исполнительный лист) алырга һәм гариза язарга тиеш булачаксыз. Алай эшләү мөмкин түгел икән, суд приставларына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Ул очракта башкару эше (исполнительное производство) ачылачак һәм шуның нигезендә эшләячәкләр. Ирегезгә һәм бухгалтерга хәбәр итеп, хезмәт хакының бер өлешен күчереп барырга кирәклеген әйтәчәкләр. Әгәр бухгалтер аны эшләмәсә, штрафка тартылачак. Элеккеге ирегез алга таба да түләмәгән очракта, милкен алырга мөмкиннәр.

«Фидакарь хезмәт өчен» медале нинди өстенлекләр, ташламалар бирә?

Узган ел «Фидакарь хезмәт өчен» медале алган идем. Аның нинди өстенлекләре, ташламалары бар икән?

Гөлия ХӘБИБРАХМАНОВА. Лаеш районы

Татарстанның Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының матбугат үзәге:
– «Фидакарь хезмәт өчен» медале түбәндәге өстенлекләр бирә: ай саен 486 сум күләмендә акчалата түләү; торак мәйданының Татарстанда билгеләнгән социаль нормасы чикләрендә торак өчен түләү чыгымнарының 50 проценты күләмендә субсидия; халык өчен хезмәт күрсәтүләрнең билгеләнгән нормативлары чикләрендә коммуналь хезмәтләр өчен түләүгә чыгымнарның 50 проценты, ә үзәктән җылытылмаган йортларда яшәүчеләргә – халыкка сату өчен билгеләнгән нормалар чикләрендә сатып алына торган ягулык бәясе һәм әлеге ягулыкны китерү буенча транспорт хезмәтләре өчен түләүгә чыгымнарның 50 проценты күләмендә субсидия; абонентка даими файдалануга бирелгән телефон элемтәсе линия челтәрләре, радио, коллектив антенна өчен чыгымнарын тулысынча каплау каралган.

Фикер

Мөмкинлек бар!

Дәрвишләр бистәсендә «Бәхетле» кибетенең эшен туктатуы турында хәбәр бар. Бинасы сатылачак, имеш, бәясе дә билгеле. Бу бина бөтен скверны туздырып, зур итеп салынган иде. Кемдер бөкресен чыгарып эшләгән акчага салынмагандыр инде ул. Бина бистәнең уртасында, олы юл буенда утыра. Аннан ерак түгел калкулыкта ун катлы йорт биеклегендә алтын белән бизәлгән чиркәү кукыраеп утыра. Мәчет тә ерак түгел. Менә шушы яхшы урында татар халкының сынлы сәнгать музее ачып булмас микән. Рада Нигъмәтуллина исемен дә бирергә кирәк булыр.

«ВТ» газетасы берничә мәртәбә бу турыда сүз кузгатты, гамәлгә ашыручы булмады. Менә хәзер күктән төшкән мөмкинлек бар. Сәнгать остасы үзе исән чакта без моны эшли алмадык. Хәзер кулга алып, Тукай бүләге лауреаты Рада Нигъмәтуллина һәм аның гаиләсенең күпьеллык хезмәтен якты дөньяга чыгарсак, һичшиксез, саваплы булыр идек. Бөтен гаиләсен сынлы сәнгатькә багышлаган очрак дөньяда юк бит ул. Нигә без, татарлар, үз кадеребезне үзебез белмибез?

Әнис ЗАРИПОВ. Казан

Укучы сүзе

БАТЫРЛЫККА СОКЛАНУ

Бу юлдан узган саен йөрәк әрни, күн дә карап узам. Сезгә мәңгелек Дан, Илемнең Батыр уллары!!!

Наилә ЗАҺИРОВА

ЫРЫМ-ШЫРЫМГА ЫШАНУ НӘРСӘГӘ КИТЕРӘ?

Кара мәче бозымнан саклый, дигәннәр. Бусагага басарга ярамый, утырсаң, буең бәләкәй кала, үсми, дип кисәтә иде әбекәйләр. Мифологик нигезләре бар ышану-юрауларның, дөнья нигә дистә мең еллар дәвам итә бит. Алар барысы да – халык акылы, тәҗрибәсе. Ул дистә мең елларны һәм дә мәңгесилекне, тарихны сызып ташлап кына булмаган кебек, кире кагарга, сызып ташларга ярамый. Бу меңьеллык белән генә исәпләнми бит әле кешелек тарихы. Әкиятләр дә буштан гына килеп чыкмаган. Һәр акыл артында олы тәҗрибә тора. Булмас димә, дөнья бу.

Миләүшә ӘХМӘТҖАНОВА

ЧАРАСЫЗЛЫК

Әнкәйләр гомер буе авыр эштә – фермада булдылар. Ул вакытта күпчелек кул хезмәте бит әле. Сыерларны кырып юу, көянтәчиләк белән барда ташу дисеңме… Сыерлар торагын чистарту булсыным. Санап бетерерлек түгел бит хезмәтләрен. Ә түләүгә килгәндә… Элек тә күп түгел иде инде ул. Иң зур хезмәт хакы авыл хуҗалыгында эшләүчеләрнеке булырга тиеш югыйсә. Таң атмас борын эштә бит алар. Тынгысыз, авыр, ялсыз эш аларныкы! Акчасын да лаеклы түләсеннәр!

Гөлнур ШӘМСЕТДИНОВА

НИКАХ УКУЧЫ МУЛЛАНЫҢ ХАТЫНЫ: «ХӘЗРӘТНЕҢ ҮЗ ТАКСАСЫ БАР, ФӘЛӘН МЕҢ СУМ ТҮЛӘГЕЗ!»

Туй үткәргәндә тамадага (+фотограф, оператор) ничә сум сорасалар да, беркем дә санамый, исәпләми. Кирәкме тамада, юкмы, ул турыда беркем дә уйламый. Булсын, җәл түгел, иң мөһиме – кешедән ким булмасын! Ә бит мулла – шул ук тамада: матур, аңлаешлы итеп вәгазен сөйли, Корьән укый, мәҗлесне алып бара, тормышны Аллаһы Тәгалә кушканча алып барырга юл күрсәтә. Ләкин аңа акча бирергә кызганыч! Ә алар ничә сум хезмәт хакы ала, дип кызыксынучы бармы икән? Бигрәк тә авыл җирендә! Кеше туып, исем кушудан алып җеназага кадәр – барысы да алар өстендә. Бу – минем фикерем. Сез ничек уйлыйсыз?

Фәридә ГАРИФУЛЛИНА

ЗАРЛАНЫРГА ЯРАМЫЙ

Бик тә дөрес язгансыз. Зарланган саен зар арта. Көч барда эшлим, яшим дип яшәргә кирәк.

Фәзимә ДАУТОВА

Зөһрә САДЫЙКОВА әзерләде

18 апрель | Дүшәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10, 02.00 «Манзара». Мәгълүмати-күңел ачу программасы 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00, 22.10 «ЛУЧИК» 12+
11.00 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.05 «СВОИ» 16+
13.00 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа» 12+
14.00 «Закон. Парламент. Общество» 12+
14.45, 05.35 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00, 03.30 «Әдәби хәзинә» 6+
18.00 «Мин» 12+
19.00, 20.00 «Таяну ноктасы» 16+
21.00 «Tatarstan today. Открытый миру» 12+
22.00 «Вызов 112» 16+
23.45 «Здоровая семья: мама, папа, я» 6+
00.00 «Если хочешь быть здоровым» 12+
00.15 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Ком сәгате» 12+
03.55 «Йөрәктән – йөрәккә» (субтитрлы) 6+
04.45 «Җырлыйк әле!» 6+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ». Телесериал 12+
08.40, 23.05, 04.15 «Башваткыч» 12+
09.50 «Семь дней». Информационно-аналитическая программа 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
15.30 «Канун. Парламент. Җәмгыять» 12+
16.00, 03.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55, 03.25 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
05.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 «Жить здорово!» 16+
10.00 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера сезона. Сергей Марин, Игорь Петренко, Екатерина Вилкова. «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» (S) 16+
22.55 «Большая игра» 16+
23.55 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР»
02.45 Владимир Колганов, Родион Галюченко, Виктория Адельфина, Леонид Громов. «ОТЕЦ МАТВЕЙ» 12+

МАТЧ ТВ

10.00, 12.30, 14.55, 19.50 Новости
10.05, 12.35 Спец. репортаж 12+
10.25, 01.00 Футбол. Тинькофф Российская Премьер-лига. Обзор тура 0+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.00 «КРАЖА» 16+
15.45 «Громко». Прямой эфир
16.35 Хоккей. КХЛ. Кубок Гагарина. Прямая трансляция
19.15, 00.00 Все на Матч! Прямой эфир
19.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Наполи» – «Рома». Прямая трансляция
21.55 Футбол. Чемпионат Италии. «Аталанта» – «Верона». Прямая трансляция
00.30 Тотальный футбол 12+
02.00 Волейбол. Чемпионат России «Суперлига Paribet». Женщины. 1/4 финала. «Динамо» (Краснодар) – «Динамо-Ак Барс» (Казань) 0+
03.30 «Наши иностранцы» 12+
03.55 Новости 0+
04.00 «Владимир Крикунов. Мужик». Док. фильм 12+
05.10 «Громко» 12+

НТВ

04.55 Сериал «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.25 Боевик «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
23.30 «ПЁС» (S) 16+
03.30 «ПОРОХ И ДРОБЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.15 «Давай разведёмся!» 16+
10.20 «Тест на отцовство» 16+
12.35 «Понять. Простить» 16+
13.40 «Порча». «Зуб» 16+
14.10 «Знахарка» 16+
14.45 «Верну любимого» 16+
15.20 «ПОЛОВИНКИ НЕВОЗМОЖНОГО» 16+
19.00 «ПЕРВАЯ ЛЮБОВЬ» 16+
22.50 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3». 1-я и 2-я серии 16+
00.40 «Понять. Простить» 16+
01.30 «Порча» 16+
01.55 «Знахарка» 16+
02.20 «Верну любимого» 16+
02.45 «Тест на отцовство» 16+
04.25 «Давай разведёмся!» 16+

ЗВЕЗДА

05.05 «СМЕРТЬ ШПИОНАМ. СКРЫТЫЙ ВРАГ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.15 «БОЛЬШАЯ СЕМЬЯ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 12+
13.30, 14.05 «Разведка боем. Секретное оружие Виктора Леонова». Док. фильм 16+
14.00 Военные новости 16+
14.20 «ОБРАТНЫЙ ОТСЧЕТ» 16+
18.45 «Специальный репортаж» 16+
20.40 «Александр Невский. Последняя загадка Чудского озера». Док. фильм 16+
21.25 «Загадки века». Док. сериал. «Путь в «Сатурн» Николая Андреева». Премьера! 12+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Скрытые угрозы» с Николаем Чиндяйкиным. «Альманах №99» 16+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-4» 16+
02.05 «ПО ДАННЫМ УГОЛОВНОГО РОЗЫСКА…» 12+
03.15 «Зафронтовые разведчики». Док. сериал 16+
03.55 «ОБРАТНЫЙ ОТСЧЕТ» 16+

19 апрель | Сишәмбе

ВГТРК ТАТАРСТАН

05.05, 06.05, 07.05, 08.05 «Вести-Татарстан. Погода»
05.35, 06.35, 07.35, 08.35 «Вести-Татарстан. Утро»
09.00 «Яңалыклар. Татарстан»
09.30 «Хәерле көн, Татарстан!»
14.30, 21.05 «Вести-Татарстан»

ТНВ ТАТАРСТАН – ЯҢА ГАСЫР

06.00, 07.10 «Манзара» 6+
07.00, 18.30, 20.30, 05.50 Татарстан хәбәрләре 12+
08.00, 14.30, 19.30, 21.30 Новости Татарстана 12+
08.10 «Здравствуйте!» 12+
09.00, 17.00 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
10.00, 22.10 «ЛУЧИК» 12+
11.00 «Фолиант в столетнем переплёте» 12+
11.15 «Память сердца» 12+
11.30, 16.30 «Татарлар» 12+
12.00, 23.05 «СВОИ» 16+
13.00 «Туган җир» 12+
13.30 «Юлчы» 6+
14.00 «Путь» 12+
14.15 «Не от мира сего…» 12+
14.45 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
15.15 «Шаян ТВ» тәкъдим итә. «Уймак» һәм «Сәйлән» 0+
16.00 «Ватандашлар» 12+
18.00 «Казаннан – казанга» 12+
19.00, 01.30 «Таяну ноктасы» 16+
20.00, 22.00 «Вызов 112» 16+
20.15 «Күчтәнәч» 0+
21.00 «Ватандашлар» 12+
23.50 «Видеоспорт» 12+
00.15 «Соотечественники» 12+
00.40 «Здоровая семья: мама,папа,я» 6+
00.55 «Если хочешь быть здоровым» 12+
01.10 «Не от мира сего…» 12+

ТНВ ТНВ-ПЛАНЕТА

06.00, 13.00, 01.05 «Манзара» 6+
08.00, 17.00, 21.25, 00.15 «БЕР-БЕР ХӘЛ» 12+
08.40, 23.05 «Җырлыйк әле!» 6+
09.40 «Туган җир» 12+
10.30, 20.30 «Халкым минем» 12+
11.00, 15.00, 18.00, 21.00, 00.00 «Яңалыклар» 12+
11.30, 17.30, 19.35, 00.40 «Татарлар» 12+
12.05, 18.20, 22.20 «СИҢА КАЙТАМ» 12+
13.00 «Манзара». Мәгълүмати- күңел ачу программасы 6+
15.30 «Тамчы-шоу» 6+
16.00 «Әдәби хәзинә» (субтитрлы) 12+
16.30 «Шаян ТВ» тәкъдим итә… 6+
19.10, 21.55 «Тибрәнә җыр дулкыннары» 6+
20.00 «Таяну ноктасы» 16+
01.05 «Әй, язмыш, язмыш…» (субтитрлы) 12+

1 КАНАЛ

05.00 Телеканал «Доброе утро»
09.00 Новости
09.20 «Жить здорово!» 16+
10.00 Информационный канал 16+
12.00 Новости (с субтитрами)
12.15 Информационный канал 16+
15.00 Новости (с субтитрами)
15.15 Информационный канал 16+
18.00 Вечерние новости (с субтитрами)
18.20 Информационный канал 16+
21.00 «Время»
22.00 Премьера сезона. «НАЧАЛЬНИК РАЗВЕДКИ» (S) 16+
23.00 «Большая игра» 16+
00.00 Информационный канал 16+
03.00 Новости
03.05 Информационный канал 16+

РОССИЯ 1

05.00, 09.30 «Утро России»
09.00 Местное время. Вести-Татарстан
09.55 «О самом главном». Ток-шоу 12+
11.00, 14.00, 17.00, 20.00 Вести
11.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
14.30 Местное время. Вести-Татарстан
14.55 «Кто против?» Ток-шоу 12+
17.30 «60 минут». Ток-шоу 12+
21.05 Местное время. Вести-Татарстан
21.20 Русская серия. Премьера. Юлия Хлынина, Александр Балуев, Агриппина Стеклова, Алексей Агранович. «ЕЛИЗАВЕТА» 16+
22.20 «Вечер» 12+
01.00 «ЗЕМСКИЙ ДОКТОР»
02.45 Владимир Колганов, Родион Галюченко «ОТЕЦ МАТВЕЙ» 12+

МАТЧ ТВ

06.00, 09.00, 12.30, 14.55, 17.35 Новости
06.05, 19.30, 23.45 Все на Матч! Прямой эфир
09.05, 12.35 Спец. репортаж 12+
09.25 «КРАЖА» 16+
11.10, 03.00 Матч! Парад 16+
11.30 «Есть тема!» Прямой эфир
12.55 «Главная дорога» 16+
14.00, 15.00 «СПАРТА» 16+
15.45, 17.40 «СЛЕД ПИРАНЬИ» 16+
19.55 Футбол. Бетсити Кубок России. 1/4 финала. «Балтика» (Калининград) – «Динамо» (Москва). Прямая трансляция
21.55 Футбол. Кубок Германии. 1/2 финала. «Гамбург» – «Фрайбург». Прямая трансляция
00.30 «Есть тема!» 12+
00.50 Профессиональный бокс. Д. Бивол – Д. Вегас. Д. Кудряшов – В. Мероро. Трансляция из Москвы 16+
02.00 «Спорт высоких технологий». Док. фильм 12+
03.30 «Правила игры» 12+
03.55 Новости 0+
04.00 Баскетбол. Евролига. Мужчины. 1/4 финала. «Барселона» (Испания) – «Бавария» (Германия) 0+

НТВ

05.00 «ВОЗВРАЩЕНИЕ МУХТАРА» (S) 16+
06.30 «Утро. Самое лучшее» 16+
08.00, 10.00, 13.00, 16.00, 19.00, 23.00 Сегодня
08.25, 10.35 «МОРСКИЕ ДЬЯВОЛЫ. РУБЕЖИ РОДИНЫ» (S) 16+
13.25 Чрезвычайное происшествие
14.00 «Место встречи»
16.45 «За гранью» (S) 16+
17.50 «ДНК» (S) 16+
20.00 Премьера. «ПОЛИЦЕЙСКОЕ БРАТСТВО» (S) 16+
23.30 «ПЁС» (S) 16+
03.10 Их нравы 0+
03.25 «ПОРОХ И ДРОБЬ» 16+

ДОМАШНИЙ

06.30 «По делам несовершеннолетних» 16+
09.00 «Давай разведёмся!» 16+
10.00 «Тест на отцовство» 16+
12.15 «Понять. Простить» 16+
13.20 «Порча». «Огненное кольцо» 16+
13.50 «Знахарка» 16+
14.25 «Верну любимого» 16+
15.00 «СЕМЕЙНОЕ ДЕЛО» 16+
19.00 «СЕРДЦЕ РИТЫ» 16+
22.45 «ЖЕНСКИЙ ДОКТОР 3». 3-я и 4-я серии 16+
00.35 «Понять. Простить» 16+
01.25 «Порча» 16+
01.50 «Знахарка» 16+
02.15 «Верну любимого» 16+
02.40 «Тест на отцовство» 16+
04.20 «Давай разведёмся!» 16+
05.15 «По делам несовершеннолетних» 16+

ЗВЕЗДА

05.20 «ОБРАТНЫЙ ОТСЧЕТ» 16+
07.00 «Сегодня утром» 12+
09.00, 13.00, 18.00, 22.15 Новости дня 16+
09.15, 18.45 «Спец. репортаж» 16+
09.35 «ПРОСТАЯ ИСТОРИЯ» 12+
11.20, 19.00 «Открытый эфир» 12+
13.30, 03.10 «Сделано в СССР». Док. сериал 12+
13.45, 14.05 «СМЕРШ» 16+
14.00 Военные новости 16+
20.40 «Последний воин СМЕРШа». Док. фильм 16+
21.25 «Улика из прошлого». Премьера! 16+
22.30 «Между тем» 12+
22.55 «Легенды армии» с Александром Маршалом. Евдокия Завалий. Премьера! 12+
23.40 «ЗАКОН И ПОРЯДОК. ОТДЕЛ ОПЕРАТИВНЫХ РАССЛЕДОВАНИЙ-4» 16+
02.05 «Генрих Гиммлер. Апостол дьявола». Док. фильм 12+
02.50 «Хроника Победы». Док. сериал 16+
03.25 «СМЕРШ» 16+

ЙОЛДЫЗНАМӘ 18–24 АПРЕЛЬ

КУЧКАР (21.03 – 20.04)
Акча турында күбрәк уйларга туры килер. Ни хикмәт: тиз генә баеп китү юллары шуның кадәр җиңел ачылыр… Артыгын кабаланмаска гына кирәк. Юкса кайбер мөмкинлекләр игътибардан читтә калырга мөмкин.

ҮГЕЗБОЗАУ (21.04 – 20.05)
Атнаның беренче яртысында ниндидер комачаулык-чикләү сизәрсез. Кемнәрнеңдер үзегезгә аяк чалырга маташуы да, күңелегездә туган шикләр дә булырга мөмкин бу. Язгы кояшка ышанып, артык җиңел киенмәгез: салкын тидерү куркынычы бар.

ИГЕЗӘКЛӘР (21.05 – 21.06)
Сөеклегез белән уртак тел табу авыррак булыр. Әмма нәтиҗә чыгарырга ашыгасы түгел! Бер-ике көннән соң үзара кытыршылыкларның эзе дә калмас. Атна ахырында үзегезгә кагылышлы әйбәт яңалык ишетелер.

КЫСЛА (22.06 – 22.07)
Көнкүрештә моңарчы кичектерелеп килгән проблемалар янә баш калкытыр. Тик аларны хәл итәргә ашыкмагыз. Хәзер сезнең бар теләгегез – берникадәр вакытка ялгызлыкта, тынычлыкта калу…

АРЫСЛАН (23.07 – 23.08)
Эштә зур максатлар куярга вакыт, дип кисәтә йолдызлар. Атна уртасында зарыгып көтелгән бер вакыйга булыр һәм ул тормышыгызның бермә-бер яхшыруына өмет уятыр. Якшәмбедә кемнәргәдер ярдәм кулы сузарга кирәк булыр. Шуңа күрә рәхәтләнеп ял итү турында уйламагыз да.

КЫЗ (24.08 – 22.09)
Кайчы, пычак ише әйберләр белән саграк эш итегез: җәрәхәтләнү куркынычы бар. Тагын бер проблема – ул да булса акча җитмәү. Бераз түзеп торырга туры килер: офыкта бик тә матур мөмкинлекләр шәйләнә…

ҮЛЧӘҮ (23.09 – 23.10)
Атнаның беренче яртысы киеренкерәк рухта узар. Хезмәт урынында баш күтәрми эшләргә туры килсә, өйдә бераз тынгысызлык булып алыр. Борчылмагыз: атна ахырына таба барысы да көйләнер һәм көтмәгәндә ярыйсы гына уңышлар килеп чыгар.

ЧАЯН (24.10 – 22.11)
Бу чорда күңелсезрәк, әмма кирәкле эшләр башкарырга туры килмәгәе. Риза булып эшләргә тырышыгыз: шулай икән, барысы да җиңел генә булыр. Ялларда кунаклар килеп төшәр.

УКЧЫ (23.11 – 21.12)
Балаларыгыз шәп кенә уңышлары белән сөендерер. Өстәвенә керемегез артуга өметләндергән хәлләр дә булып алыр. Кыскасы, бик уңышлы, әйбәт чор.

КӘҖӘМӨГЕЗ (22.12 – 20.01)
Эштә фикерегезне ачыктан-ачык әйтүдән курыкмагыз: сезне, һичшиксез, аңлаячаклар. Ә менә наданрак кеше белән бәхәсләшүдән мәгънә юк. Нерв күзәнәкләрен юкка туздырудан гайре, бернигә китермәячәк бу.

СУКОЯР (21.01 – 19.02)
Эштә дә, өйдә дә вак-төяк мәшәкатьләр чыгып кына торыр. Шуңа күрә армый-талмый бил бөгәргә туры килер. Хафаланмагыз: инде бик тиздән хезмәтегезнең шәп кенә әҗере күренер.

БАЛЫК (20.02 – 20.03)
Бу атнада төп мәшәкатьләрегез акчага бәйле булыр. Нәрсәдер сатып алу яки көнкүреш техникасына ашыгыч ремонт ясату таләп ителер кебек. Балаларга да чыгымнар артыр.

КОМБИКОРМА, ЗЕРНО
Комбикорм для **БРОЙЛЕРА ФИНИШ** (от 26 дней)
25 кг – 1070 р/мешок
Комбикорм для **БРОЙЛЕРА СТАРТ** (0-25 дней)
25 кг – 1350 р/мешок
Полный ассортимент: agroline1.ru
Казань, Техническая, 15.
тел.: +792-704-99-706
Реклама



РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

Динә
ГЫЙЛАҖИЕВА

ЧИСТАЛЫК ҺӘМ ТӘРТИП КОТКАРА

Тәндә анда-санда чыккан папиллома, сөялләр күбебезгә яхшы таныш. Алар, нигездә, ВПЧ (вирус папилломы человека) вирусы йоктыру аркасында пәйда була. Бу вирус нәрсәсе белән куркыныч? Ул кайчан яман шешкә әверелә? Тәнендә папиллома, сөялләр булган кешегә кояшта кызынырга ярыймы?

Табиб-гинеколог Булат НУРИЕВ папилломага бәйле төп сорауларга ачыклык кертте.

:: ВПЧ вирусы ни дәрәҗәдә куркыныч?
– Папиллома вирусы (ВПЧ) – ДНК вирусы. Ул Җир шарында яшәүчеләрнең 70–80 процентында очрый. Папиллома вирусы тән тиресен яки лайлалы тышчаны зарарлый. Әлеге вирус аркасында кешенең тәненә папиллома һәм сөял чыгарга мөмкин. Ул яман шеш пәйда булу ихтималын да арттыра. Әйтик, аналык муентыгы яман шешен нәкъ менә шушы вирус китереп чыгара. Кеше әлеге вирусны йоктыра, ул аналык муентыгы күзәнәкләрендә үзгәрешләр барлыкка китерә һәм ахыр чиктә яман шешкә әверелә. Моннан тыш папиллома вирусы җенес әгъзасы, арт юл һәм йоткылык яман шешенә дә китерә ала.

:: Организмга ВПЧ эләксә, яман шеш белән авыру котылгысыз, димәк?
– Юк, мондый төр вирус булган организмда һичшиксез яман шеш килеп чыгачак дигән сүз түгел. Вирусның 150ләп төре билгеле. Аларның кайберләре генә (16 һәм 18 нче типтагы ВПЧ) яман шеш барлыкка китерә ала. Калганнары, нигездә, тәндә төрле папиллома, сөял генә чыгара. Дөрес, организмында 16 нчы, 18 нче типтагы ВПЧ вирусы булган кеше дә яман шеш белән авырмаска мөмкин. Ник дигәндә, еш кына кешенең иммун системасы 2–3 ел эчендә вирусны үзленнән җиңә, юкка чыгара.

:: ВПЧ вирусы организмга ни рәвешле эләгә?
– Ул, нигездә, җенси юл аша йога. Чит кешенең шәхси гигиена әйберләреннән файдаланган очракта да эләгә ала.

:: Кул, муен, йөз кебек ачык урыннарга чыккан папилломалар да була. Алар кешедән кешегә йога аламы?
– Әйе, йога ала. Кеше белән күрешкәндә, кочаклашканда андый куркыныч арта.

:: Кеше үзендә ВПЧ вирусы барлыгын нинди билгеләр буенча чамаларга тиеш?
– Беренче мәлдә вирус үзен берничек тә сиздермәскә мөмкин. Бу чорда организмда еш кына ниндидер җитди үзгәрешләр – сызлау-авырту, бүлендекләр күзәтелми. Бераздан исә тәндә папиллома, сөял пәйда булырга мөмкин. Әмма анысы да бик сирәк кешедә генә очрый.

:: ВПЧга анализны еш тапшырырга кирәкме?
– ВПЧ анализын җенси тормыш башланганнан соң өч ел узгач тапшыра башларга кирәк. Әгәр анализ аналык җиңсәсендәге күзәнәкләрдә үзгәрешләр барлыгын күрсәтсә, тиз арада чарасын күреп, аны яман шешкә кадәр җиткермичә калып була. Менә шушы башлангыч чорны күреп калу бик мөһим. Шуңа күрә елга бер тапкыр онкоцитологиягә мазок тапшыру хәерле.

shutterstock.com

ВПЧ ЙОКТЫРУДАН САКЛАНУ ЫСУЛЛАРЫ
✱Вирус, нигездә, җенси юл белән күчә. Шуңа күрә аннан саклану өчен, презерватив куллану хәерле.
✱Шәхси гигиена кагыйдәләрен дә онытмаска кирәк. Җәмәгать мунчасы, бассейн, сауна кебек урыннарга үз сөлгең, эчке аяк киемең белән барырга, утырганда аска чүпрәк салырга кирәк.
✱ВПЧга каршы вакцина ясату да файдалы. Дөресрәге, вирустан саклаучы иң нәтиҗәле ысул бу. Ул әлеге вирусның яман шеш китереп чыгару ихтималы зур булган төрләреннән генә саклый. Барлык төрләреннән үк саклап бетерә алмый. Аны 11–14 яшьтә ясатсаң хәерле. Җенси тормыш белән яши башлаганнан соң әлеге төр вакцинаны ясатудан мәгънә юк.

:: Папиллома вирусы анадан балага күчә аламы?
– Бу вирус сабыйга туганда эләгергә мөмкин. Әмма мондый очраклар сирәк күзәтелә.

:: Организмнан ВПЧны тулысынча юкка чыгарып буламы?
– Даруханәләрдә сатылган ниндидер махсус дарулар ярдәмендә генә ВПЧ вирусыннан котылып булмый. Җир йөзендә әлегә андый бер генә дару да юк. Шуңа күрә бу – акча әрәм итү генә. Әйткәнемчә, көчле иммунитет бу вирусны өч ел дигәндә үзе җиңә ала. ВПЧ вирусы аркасында пәйда булган сөял, папилломаларны яндырырга мөмкин.

:: Тәнендә папиллома, сөялләре булган кешегә кояшта кызынырга ярыймы?
– Бу очракта кояшта кызынуның бернинди зыяны да юк. Һәрхәлдә, кояш, ультрашәмәхә нурларның папиллома, сөялләргә зарар салуы фәнни яктан расланмаган.

Белеп тор!

Ачы үлән аппетитны яхшырта

Өч өлеш әремгә бер өлеш меңъяфрак (тысячелистник) кушып болгатыгыз. Бер аш кашыгы шул үлән катнашмасына бер стакан кайнап торган су салыгыз да шуны 20 минут томалап тотып сөзегез. Төнәтмәне ашарга 15–20 минут кала, бер аш кашыгы күләмендә эчеп куегыз.

Ачы торма бронхиттан дәвалый

Балаларны дәвалау өчен ул болай ясала: иң элек ачы торманы вак шакмаклап турагыз. Шуны кәстрүлгә салып, өстенә шикәр комы сибегез. Кәстрүлне капкач белән ябып, мичтә ике сәгать пешерегез. Аннары барлыкка килгән сокны сөзеп, кечкенә шешәгә тутырыгыз. Балага әлеге сокны ашар алдыннан көнгә өч-дүрт тапкыр икешәр чәй кашыгы күләмендә эчерергә кирәк.

pixabay.com

Үзем сынадым

Кәбестә яфрагы булышты

Шактый озак ютәлләп интектем. Нәрсә генә эчеп, кулланып карасам да, ахыргача дәвалап бетереп булмады. Ютәлдән гап-гади кәбестә яфрагы ярдәм итте бит! Шаккаттым. Кәбестә яфрагын кайнар суга салып, 1–2 минут тотам да, өстенә бал ягып, күкрәк өстенә куеп йокларга ятам. Кысып тора торган футболка кисән, төн буе урыныннан кучми ул. Дүрт көндә файдасын күрдем шуның.

Алсу САФИНА. Арча

АВЫЗДАН ТИМЕР ТӘМЕ КИЛСӘ...

Авыздан тимер тәме килә! Бу күренешне, гадәттә, организмдагы тимер күләменең чамадан тыш артып китүе белән аңлаталар. Тик авыздан тимер тәме килү организмдагы башка үзгәрешләр турында да кисәтергә мөмкин, ди белгечләр.

▶Бу күренеш йөклелек чорында күзәтелә. Хатын-кыз үзенең әни булачагын белмичә дә йөрергә мөмкин. Тик авыздан көн саен тимер тәме килә башласа, шикләнергә җирлек бар. Табиблар моны йөкле чакта гормоннарда күзәтелгән үзгәрешләргә бәйләп аңлата. Йөклелекнең икенче өч айлыгына авыздагы тимер тәме юкка чыга, ди алар.
▶Авыздагы тимер тәме гингивит, пародонтит кебек авыз куышлыгы авырулары турында да кисәтергә мөмкин. Бу – аларның башлангыч билгесе.
▶Салкын тигәндә, борында полип, синусит булганда, колак авыртканда да авыздан тимер тәме килә ала. Сулыш юллары авырулары вакытында авыз куышлыгына, телгә эләккән лайла еш кына әнә шундый тәм бирә.
▶Авыздан тимер тәме килүнең тагын бер сәбәбе организмда цинк күләме артып китүдән яки җитмәүдән гыйбарәт. Бу минерал җитмәгәндә, күзәнәкләр акрынрак яңара. Шул сәбәпле авыздагы тәмнәр дә үзгәрә. Организмдагы цинк күләме артып киткәндә, күңел болгана, авыздан тимер тәме килә башлый.
▶Бөер, бавыр дөрес эшләмәгәндә, организмда билгеле бер матдәләр туплана. Тәкәреккә эләксә, алар шулай ук тимер тәме бирә.

ТИСКӘРЕ ЙОГЫНТЫСЫ БУЛЫРГА МӨМКИН. КУЛЛАНЫР АЛДЫННАН ТАБИБ БЕЛӘН КИҢӘШЕГЕЗ.

Валентина СЕМЕНОВА

ТАБИГАТЬ ВИТАМИНЫ

Халык язгы табигать витаминын – каен суын җыеп калырга ашыга. Нәкъ менә апрельдә, бөреләр уянганчы алып калырга кирәк аны. Сихәтле суны агачка зыян китермәслек итеп ничек җыярга һәм ничек сакларга?

Моның серләрен табигатьнең сихәтле байлыклары турында мең дә берне белүче – Арча районы Наласа авылында яшәүче Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВАдан белештек.

:: Гөлчирә ханым, бу эшне ничек башкарсаң, дөресрәк булыр?

– Мин үзем каен суы җыюны байтактан оныкларыма тапшырдым инде. Аларга болайрак өйрәттем. Агач кәүсәсен җирдән 20–40 см чамасы биеклектә бораулау белән тишеп, уентыкка нечкә көпшә урнаштырабыз һәм кәүсәгә бер литр – литр ярымлы пластик шешә бәйләп куябыз. Савыт тулгач, уентыкны томалау – шәм балавызы (шәмне яндырып) яки бакча сумаласы сылап калдыру шарт, юкса агач корырга мөмкин. Белүемчә, агачның төньякка карап торган ягында суы күбрәк була. Бер каен уртача 3 литр су бирә. Агачның бик яшь тә, карт та түгелен – кәүсәсенең диаметры 20–50 см чамасы булганын сайлап алу әйбәт.

:: Сихәтен җуймыйча, ничек сакларга икәнен дә әйтеп үтсәгез иде.

– Суыткычта да ике тәүлектән артык саклап булмый – әчи башлый. Суны катырып куярга мөмкин. Бөтнек, шалфей, мәтрүшкә ише дару үләннәре салып катырсаң, тагын да әйбәтрәк. Каен суы бу очракта ярты ел чамасы үзләген югалтмыйча диярлек саклана. Шулай ук консервлап куярга, аннан витаминлы куас ясарга да мөмкин.

:: Каен суының шифасы нидән гыйбарәт? Ул нинди авырулардан котылырга ярдәм итә?

– Ул фруктозага, минераль матдәләргә, төрле микроэлементлар һәм витаминнарга бай. Өч атна буе көненә берәр стакан каен суы эчү язгы витамин җитмәүдән, хәлсезлектән котылуга ярдәм итә. Фән нигезендә дәлилләнгән бу! Аны ашказаны, уникеилле эчәк, үт куыгы, бронхит авыруларыннан интегүчеләргә, бөердә таш булганда кулланырга киңәш итәлә. Тамак шешкәндә, авыз куышлыгы ялкынсынганда тамакны каен суы белән чайкап алу сихәт бирә. Шулай ук бетчәләрдән, экзема, дерматит, псориаз кебек тән тиресе авыруларыннан котылуга, җәрәхәтләрне тизәтүгә ярдәм итә. Ләкин табиблар аны балаларга 1 яшькә кадәр эчермәскә киңәш итә.

КАЕН СУЫННАН – КУАС

Гөлчирә НӘҖМЕТДИНОВА рецептлары

▶ 10 литр каен суын сөзеп, шуңа 3–4 лимон согы сыгып салабыз. 50 грамм чүпрә, 3–4 бөртек йөзем, 40 грамм бал өстәп болгатабыз. Куас 3–4 көннән соң өлгерә. Әзер эчемлекне банкаларга сөзеп тутырабыз һәм салкынча урынга куябыз.

▶ Өч литрлы пыяла банкага 2,5 литр каен суы тутырабыз. Шуңа 50шәр грамм йөзем һәм каһвә бөртекләре (кыздырып), ярты стакан шикәр комы, 2–3 кисәк киптерелгән арыш икмәге катысын өстәп, банка авызына резин пирчәткә кидереп куябыз. Пирчәткә башта тулып кабара. Шиңеп төшкәч, куас әзер дигән сүз. Эчемлекне сөзеп, салкынча урынга урнаштырабыз.

Тәмле булсын!

Җимеш бәлеше

Зөлфирә ШӘЙДУЛЛИНА рецепты

Камыр өчен: *1 стакан җылымса сөт, ярты стакан үсемлек мае, 1 кашык майонез, ярты аш кашыгы тоз, 3 аш кашыгы шикәр комы, ярты чәй кашыгы сода, 1 йомырка.*

Яхшылап болгатабыз һәм әз-әзләп он салып, камыр басабыз.

Эчлеге өчен: *200–300 грамм чамасы тура (корт), дөге (бәлешнең зурлыгына карап – 2–2,5 стакан чамасы), 120–200әр грамм чамасы курага һәм кара җимеш, эретелгән атланмай.*

Камырны (ике өлешкә бүләбез, кечерәк өлеше – бәлеш капкачы өчен) җәеп, табага урнаштырабыз. Төбенә тигез итеп бер катлам корт җәеп салабыз. Бүртерелгән дөге белән җимешкә ярты стакан чамасы шикәр комы, 2–3 аш кашыгы эретелгән атланмай өстәп болгатабыз һәм корт өстенә бушатабыз. Өстен тигезлибез. Камыр җәймәсе белән каплап, бөгеп куябыз. 180 градуска җылытылган газ мичена куеп, 30–40 минут пешерәбез. Пешкәч, ашар алдыннан капкачын ачып, алдан эретеп куелган ярты стакан майны бәлешкә агызабыз.

Укучы киңәше

«Кураж» – тәмле сорт

Узган елда апам кыярның шушы сортын утыртырга киңәш иткән иде. Кечкенә генә түтәлгә 4–5 орлык утырттым – кыярын җыеп бетерерлек булмады! Өстәвенә бик тәмле дә икән. Ә иң гаҗәпләндергәне – җәй ахырында башка сортлар инде әллә кайчан саргаеп утырса, «Кураж» әле һаман яшел иде. Ә сентябрьдә теплицада шушы гибрид кына утырып калды. Төнге температура нульгә якынлашканда да, әле һаман кыяр җыюны дәвам иттек. Соңгы ярты чиләк «Кураж»ны көчле кырау төшкәннән соң җыеп алдык.

Тагын «Престиж» һәм «Ажур»ны да утыртырга киңәш итәм. Түтәлдә, гибридлар белән бергә, бал кортлары ярдәмендә серкәләндерелүче сортларның (әйтик, «Малыш» яки «Кустовой») да үсеп утыруы әйбәт. Шулай бергә булганда, алар көчлерәк үсә.

Ташкабакка килгәндә, «Цукеша» һәм «Черный красавец» сортларын утыртырга тәкъдим итәм. Ашау өчен дә, консервлап кую өчен дә менә дигән!

Әлфинур НИЗАМИЕВА.
Казан

Бакчачыга

– Корткычлардан котылу өчен, җимеш агачларына бордо катнашмасын ничек ясап сибәргә?

Лилия НУРГАТИНА.
Балык Бистәсе районы

Сорауга Эльмира ИСХАКОВА җавап бирә:

– 100 граммлы катнашма 1 процентлы дип атала. 3 процентлысын ясау өчен, өч кап алырга кирәк. 3 процентлысын агач бөреләре ачылганчы сиптерәсе. Бу вакытка өлгермәсәгез, 1 процентлысын бөркисе. Ике савытка 1әр литр кайнар су агызып, берсенә – бакыр купоросын, икенчесенә известь салып, яхшылап эретәбез. Шуларны 10 литрлы чиләккә бушатабыз: башта известьлесен, аннан – бакыр купорослысын. Аңа 8 литр салкын су өстибез. Барлыгы 10 литр килеп чыга. Яхшылап болгатабыз. Сиптергеч тишекләре тыгылмасын өчен, иске иләк яки бернечә кат марля аша сөзеп салабыз. Алмагачларга, гомумән барлык җиләк-җимеш куакларына, шул исәптән виноградка бөркибез.

Игътибар: эремәне тимер чиләктә ясарга ярамый!

Киңәш-табыш

БАЛЫК КЫЗДЫРУ СЕРЕ

Балыкны юып, табага салырга 10–15 минут кала, кәгазь сөлге белән яхшылап киптерергә һәм шундук тозларга кирәк. Болай эшләгәндә, балык кисәкләргә таркалмыйча, алсуланып кыза. Ә инде чикләвекле (төелгән) онда әвәләп тә кыздырсагыз, бетенләй дә телеңне йотарлык тәмле булачак!

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА

ЮМАРТЛЫК БӘРӘКӘТ КИТЕРӘ

Ислам дине кешеләрне юмарт булырга өнди, юмартлыкны адәм баласындагы иң күркәм сыйфатларның берсе итеп күрсәтә. Юмартлыкның чиге бармы? Кемнәргә карата аеруча юмарт булу кирәк? Сәдака өләшү, бурычка акча биреп тору да юмартлыктан саналамы?

Бу һәм башка сорауларга җавапны Казандагы «Мәрҗани» мәчетенең икенче имамы Айморат хәзрәт ХАҖИЕВ белән эзләдек.

:: Ни өчен юмартлык ислам динендә иң күркәм сыйфатларның берсе булып санала?

– Юмартлык ул – бәрәкәт. Ни өчен? Аллаһы Тәгалә бу дөньяның тәртибен шулай корган: син юмарт булсаң, синең шул юмартлыктан чыккан өлешең артып торыр, беркайчан да кимемәс. Юмарт кеше – гадел кеше. Ул рәхимле, ул башкаларның хәленә керә белә. Аллаһы Тәгалә шуңа да юмарт кешене башкалар арасында өстенрәк итә, беренчелеккә күтәрә. Шуңа да бу сыйфат иң күркәм сыйфатларның берсе булып санала.

:: Юмарт кешегә нинди әҗер-савап языла?

– Һәр юмартлыгы, үзеннән чыгарган һәр өлеше өчен кешегә Аллаһы Тәгалә әҗер-савабын насыйп итәр. Әмма нинди күләмдә булыр ул – беребез дә әйтә алмый. Сансыз, бихисапсыз дип кенә әйтелә.

:: Кайбер кеше чамадан тыш юмарт. Үзе кимәсә кими, үзе ашамаса ашамый, әмма соңгысын бүтән кешегә булеп бирергә әзер. Юмартлыкның чиге буламы?

– Юмартлыкның чиге юктыр. Пәйгамбәребез (с.г.в.) чорында бик бай сәхабәләр булган. Алар бер-берсе белән юмартлыкта ярышкан, узышкан. Бу инде юмартлыкның чиге булмавын күрсәтә. Мөмкинлегенә карап, өлеш чыгарасың. Чик шул мөмкинлегеңдә генә чагыла. «Үзе кими, башкаларга бирә», – дигәннән дә, бу – пәйгамбәребез (с.г.в.) сыйфаты. Ул да инсаннарга ярдәм иткән, үз өлешен башкаларга тараткан. Үзенә иң соңгы чиратта гына алган. Юмартлыкның күркәм сыйфат булуын бу да дәлилли. Пәйгамбәребез (с.г.в.): «Сезнең берегезнең дә иманы тулы булмас, әгәр дә үзенә теләгәнне башкаларга теләмәсә», – ди. Ягъни башта син гаиләңә, якыннарыңа, дусларыңа телә, аннан соң гына үзеңне уйла. Әнә шул вакытта иманыгыз камил булыр, дип әйтелә пәйгамбәребез (с.г.в.) хәдисендә.

:: Кемгә карата аеруча юмарт булырга кирәк?

– Әлбәттә, мохтаҗларга, мөмкинлеге булмаган кешеләргә карата аеруча юмарт булырга кирәк. Хәзерге заманда шундый күренеш бара: сәдакасын-башкасын туган-тумачаларга, мөмкинлеге, маясы булган кешеләргә өләшәләр. Иң элек юмартлыкны мохтаҗларга, фәкыйрьләргә күрсәтү кирәк. Шул вакытта дөньяда тигезлек булыр иде. Пәйгамбәребез (с.г.в.) заманында да шундый күренеш булган: нисаб (зәкят түләү мәҗбүри булган минималь күләмдә мөлкәт, байлык. – **Авт.**) өләшерлек мохтаҗ-фәкыйрь таба алмаганнар. Бу нәрсәне аңлата? Ул вакытта барысына да тигез итеп өлеш чыгарылган, мохтаҗлык кичерүчеләр булмаган.

Гаиләңә, туганнарыңа, әти-әниеңә карата да юмарт булырга кирәк. Беркайчан да юмартлыкны яшерергә, чикләргә кирәкми.

:: Бурычка акча бирү дә, сәдака да – юмартлыкмы?

– Монда башка мәсьәлә. Сәдака Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен бирелә икән, бу – юмартлык билгесе. Фитыр, фидия сәдакалары бирелергә тиешле, билгеле сәдакалар санала. Ә бурычка акча бирү – юмартлык билгесе түгел. Әгәр дә әҗәткә акча алган кешегә шул бурычны Аллаһы Тәгалә ризалыгы өчен кичерсәң, юмартлык санала. Ә инде килешү нигезендә акча әйләнеше булса, юк.

:: Юмартлыкны тагын ничек күрсәтергә?

– Юмартлык дигәч тә, матди якны гына күз алдында тотабыз. Ул бит әле – рухи як та. Әйткәнемчә, пәйгамбәребез (с.г.в.) бар нәрсәне иң элек башкаларга теләгән: ризыгын да, киемен дә, гыйлемен дә... Үзең белгәнне башкаларга өйрәтәсең икән, бу да юмартлыктан санала. Шулай ук Аллаһы Тәгалә каршында сәдака да.

dumrt.ru

Ураза көндәлеге

Сез сораган идегез...

Укучыларыбызның сорауларына Айморат хәзрәт Хаҗиев ачыклык кертте.

?Язын аллергиядән интегәм. Шунлыктан тамагыма үтә күренмәле куе төкерек сыман әйбер җыела. Какырыкны йотарга ярамый, ураза бозыла, диләр. Мондый аллергияле кешеләргә нишләргә? Уразаны ташларгамы?

Әйе, андый кешеләр дә бар. Андый чакта кулъяулык йөртү хәерле булыр. Тамактан чыкканны кулъяулыкка төкерергә кирәк. Ул гел җыелып тора, бернишләтеп булмый икән, йотарга да рөхсәт ителә. Әмма төкеректә бары төкерек булырга тиеш. Кан, үлек кебек нәрсәләр булса, ураза бозылачак. Аллергия дип, уразаны ташлыйсы түгел!

pixabay.com

?Су эчмичә генә дару йотып куюу уразаны бозмый, диләр. Дөресме бу?

Юк, әлбәттә. Бу уразаны боза. Дөрес мәгълүмат түгел. Уразада шундый кагыйдә бар: тәннән тышка чыккан нәрсәләр уразаны бозмый, ә кересе – боза. Кәгазь кисәге генә йотылса да, ураза бозылган булып саналыр. Билгеле, бу гамәлне белеп, аңлы рәвештә эшләсәң. Онытылып, ялгышып булса, бозылмый. Әмма капкан кадәрен төкерергә, яңадан ниятләргә кирәк.

?Сәхәр ашагач, ир белән хатынга кочаклашып йокларга яту рөхсәт ителәме?

Кочаклашу шәһвәткә китермәсә, ярый. «Гаиләңә юмартлык күрсәтсәң, бу – сәдака», – ди пәйгамбәребез (с.г.в.) дә. Ураза тотканда җенси мөнәсәбәткә керү тыела.

Белеп тор!

Мөселман нинди була?

➤Мөселман һәр эшнең башында «Бисмилләһир-рахмәнир-рахим» дип әйтә.

➤Мөселманннар очрашканда «Әссәламегаләйкүм!» дип әйтә һәм бер-берсенә елмая.

➤Мөселман Аллаһ яраткан нәрсәләргә соклана һәм «Сөбханаллаһ!» ди.

➤Мөселман Аллаһы Тәгаләгә барча нигъмәтләре өчен шөкер итеп «Әлхәмдүлилләһ» дип әйтә.

➤Мөселман һәрвакыт Аллаһыдан хәерле эшләр, бәхет-сәгадәт сорый, һәр теләгенең соңында «Иншаллаһ» ди.

➤Мөселманның тагын бер күркәм сыйфаты – дәгъват. Ягъни үзеңдәге белемне башкаларга җиткерү һәм кешеләрне дингә, күркәм гамәлләр кылырга өндәү.

➤Чын мөселман Аллаһка гына буйсына һәм Аңа гына тәвәккәл кыла.

➤Иманлы бәндә нинди генә тормыш авырлыгына юлыкмасын, ул хәлләренең йогынтысы аның иманын үзгәртмәс.

➤Иманлы бәндә бервакытта да гайбәт сөйләмәс һәм ләгънәт укымас.

kzn.ru

Өч хәдис

«Әгәр гаделсезлеккә, шелтәле гамәлгә тап булсагыз, кулыгыз белән бу гамәлне туктатыгыз. Әгәр кулыгыз белән туктата алмасагыз, телегез, сүзегез белән бу гамәлне туктатыгыз. Әгәр сүз белән дә туктата алмасагыз, йөрәгегез белән каршы төшегез».

«Кешене ялганчы дип әйтергә аның бер ишеткәнен калганнарга сөйләве җитә».

«Дөреслектә, нинди генә хәлләрдә дә йомшак булу мөселманны бизи. Ә аның юклыгы кешене каралта».

Лилия ГЫЙМАЗОВА

ДИНАР ШӘРӘФЕТДИНОВ:

«МИНЕМ ӘТИГӘ ОХШЫЙСЫМ КИЛДЕ»

Танылган җырчы баласы булу кыенмы? Әти сүзе, әти киңәше аның өчен ни дәрәҗәдә кадерле? Бу сорауларга бүген «Ни хәл?» сәхифәсенең чираттагы кунагы – Динар ШӘРӘФЕТДИНОВ җавап бирде.

:: Ни хәл?

– Бар да яхшы, рәхмәт! Әле мин Нәҗип Җиһанов исемендәге Казан дәүләт консерваториясендә укып йөрим. Шуның белән беррәттән инде өч елдан артык Айгөл Зарипованың вокал студиясендә дәресләр алып барам.

:: Әтиең – җырчы, әниең – хореограф. Бер карасаң, иҗат юлын сайлавыңны сорарга кирәкми дә кебек...

– Кечкенә чагымнан ук әтиемнең (җырчы Дәниф Шәрәфетдинов. – **Ред.**) җырлаганын күреп, аңа сокланып үстем. Минем дә аңа охшыйсым килде. Тора-бара ул минем концертларында катнаштыра башлады. Ул чакта ук «Нинди һөнәр сайлармын икән?» дигән сорау тумый иде. Музыка мәктәбендә укыган вакытта, төрле бәйгеләрдә катнашып йөрдем. Ә соңыннан, Казанга күченеп, музыка училищесына укырга кердем. Бүген исә икенче елымны консерваториядә белем алам. Консерваториябезнең опера театрында җырлыйм һәм киләчәгемне дә музыканың шушы юнәлеше белән бәйләргә телим.

:: Тәүге тапкыр сәхнәгә чыккан көнең исеңдәме?

– Әйе. Әтинең Чаллыдагы концертында булды ул хәл. Аның «Акчарлагым» җырын башкардым мин. Ул чакта бик кечкенә булганлыктан, барын да аңлап җиткермәгәнмендер инде. Ләкин бик көчле һәм озак итеп алкышлаганнарын әле дә яхшы хәтерлим.

:: Артист һөнәренең авырлыкларын да яшьтән күреп үскәнсеңдер?

– Күпләр, арзанрак икән, димәк, сыйфаты да начаррак дип фикер йөртә. Әмма аларның бәясе бу даруны уйлап тапкан башлангыч чордагы кебек ниндидер тикшеренү, тәҗрибәләр үткәрү өчен өстәмә чыгымнар кирәк булмаганга гына арзанрак була. Авыруга булышу-булышмавы ягыннан исә алар барысы да бер дәрәҗәдә, – ди табиб.

Шулай да кайбер төр дарулар күпме генә көтсәң дә нәтиҗә бирми. Узган ел температура төшерә торган «Парацетамол» даруын эчкәч, 1,5–2 сәгать вакыт үтсә дә, температура төшмичә тилмерткән иде. Кабына игътибар итеп карагач, аның аналог дару икәнлеген аңладым. Флера ханым бу күренешне болай аңлатты. «Даруларны һәм аларның аналогларын составындагы төп матдә берләштерә. Әмма аларга кушылган ярдәмче матдәләр төрле булырга һәм организм аларны кабул итмәскә, моңарчы эчеп ияләнгән матдәне таләп итәргә мөмкин. Кайбер аналогларның шифасы тимәү әнә шуңа бәйле», – ди табиб.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

ДАРУЛАР ҺӘМ АЛАРНЫҢ АНАЛОГЛАРЫ

	ДАРУ		АНАЛОГЫ	
төре	исеме	уртача бәясе (сумнарда)	исеме	уртача бәясе (сумнарда)
вируслы авырулардан	Амиксин	670	Лавомакс	461
авыртуны баса	Баралгин	392	Аналгин	55
тән тиресе	Бепантен	960	Декспантенол	256
авыртуны баса	Вольтарен	645	Диклофенак	124
аллергиядән	Зиртек	213	Цетринакс	72
калкансыман биз авыруыннан	Йодомарин	224	Калий йодиды	90
ютәлдән	Лазолван	390	Амброксол	59
ашкайнату эшчәнлеген яхшырта	Мезим	299	Панкреатин	43
эч авыртудан	Омез	162	Омепразол	88
йөрәк даруы	Панангин	374	Аспаркам	61
буыннар сызлаганнан	Фастум-гель	459	Кетопрофен	125
кан басымын көйли	Энап	401	Эналаприл	47
калкансыман биз авыруыннан	L-тироксин	360	Эутирокс	120
вируслы авыруларга каршы	Эргоферон	510	Гриппферон	300

Фәния
ӘХМӘТҖАНОВА

БАТЫР ЕГЕТ БАТЫРШИН

1934 ЕЛНЫҢ 16 АПРЕЛЕНДӘ СОВЕТЛАР СОЮЗЫ ГЕРОЕ ИСЕМЕ ГАМӘЛГӘ КУЕЛА. ТАТАРЛАР АРАСЫНДА БУ МАКТАУЛЫ ИСЕМГӘ БЕРЕНЧЕ БУЛЫП ГЫЙЛЬФАН ӘБҮБӘКЕР УЛЫ БАТЫРШИН ЛАЕК БУЛА

Милләттәшебезгә Советлар Союзы Герое исеме 1938 елны Хәсән күле буенда япон милитаристларына каршы көрәшкәндә күрсәткән батырлыгы өчен бирелә. Каһарман Гыйльфан Батыршин Бөек Ватан сугышында да башыннан ахырына кадәр катнаша. Аны 1947 елны Токиода Япония хәрбиләрен хөкем итү мәхкәмәсе утырышына чакыралар. Шуннан кайтышлый, авиация фаҗигасендә һәлак була.

Хәсән күле

«Ил геройлары» сайтында милләттәшебезнең батырлыгы турында мондый юллар бар. «1938 елның 31 июлендә Посьетск чик сакчылары отрядының маневр төркемендә отделение командиры, кече командир Г.Ә.Батыршин, Заозерный биеклеген (Хәсән күленең көньяк яры) алганда, команда пунктын һөҗүмнән саклап, дошманның ут нокталарын юкка чыгара. Японнар чик сакчыларын камап алырга уйлаганда, Батыршин һөҗүм итүчеләрне үзенә җәлеп итә. Яраланура карамастан, дошман уты астында авыр хәлдәге командирын эзләп таба һәм сугыш кырыннан алып чыга. 1938 елның 1 августына каршы төндә аның отделениесе сан ягыннан күпкә артык булган дошманга каршы уңышлы сугыш алып бара. СССР дәүләт чиген саклауда күрсәткән батырлыгы өчен кече командир Батыршин Гыйльфан Әбүбәкер улына Советлар Союзы Герое исеме бирелә, Ленин ордены, «Алтын Йолдыз» медале белән бүләкләнә».

Хәсән күле янындагы сугышлар 13 көн дәвам итә. Батыршин, җилкәсенә яралыларны салып, 500 метр киңлектәге күлне 9 тапкыр кичә. Чик сакчылары арасында бу олы бүләккә ул беренчеләрдән булып лаек була.

Ямаширмә егете

Украинада туса да, без геройны зур горурлык белән якташыбыз дип әйтә алабыз: аның әнисе Фатыйма тумышы белән Биектау районындагы Ямаширмә авылыннан. Хәер, язучы Шамил Рәкыйповның «Таңнар бездә матурмы?» китабында язылганча, ул үзе турында иптәшләре янында да, командирлары алдында да, мин – Татарстаннан, дип йөри. Авылдашлары әйтүенчә, җәй айларын гел авылда үткәргәнгәдер, күрәсең, Гыйльфан Батыршинның исеме Ямаширмә авылының халык саны алу кенәгәсендә дә бар. 1920 нче елларда гаилә авылга кайта, соңыннан Казанга күченә. 7 нче сыйныфны тәмамлагач, Гыйльфан «Пишмаш» заводында эшли башлый. Ни сәбәпледер, яңадан Украинага китә. Лисичанск шәһәрендәге шахтага эшкә урнаша, берләттән тау техникумында укый, спорт белән шөгыльләнә. Шуннан Ерак Көнчыгышка, Кызыл Армия сафларына чакырыла.

«Батыршин маршы»

Гыйльфан Ямаширмәгә, инде Герой булып, 1939 елны кайта. Авылдашлары аны бик җылы каршылый, Хәсән күле буендагы чик сакчыларының каһарманлыклары турында сөйләгәннәрен зур кызыксыну белән тыңлыйлар. Хәтта ат бүләк итәләр. Әмма аңа тынычлап ял итәргә туры килми. Бертуктаусыз кунакка чакыралар. Беренче көнне үк «Пишмаш» заводында да көтәләр. Шунда ул үзенең верстагын да күреп ала. Анда «Бу слесарь верстагы артында Советлар Союзы Герое Гыйльфан Батыршин эшләде» дип язылган була. «Кая карама таныш йөзләр. Барысын да кысып кочаклыйсы, каты итеп кулларын кысасы, элеккеге кебек туйганчы рәхәтләнеп сөйләшәсе килә...» – дип сөйли ул бу очрашу хакында. Соңыннан театрга чакыру билетлары тапшыралар. Анда күренекле шагыйрьләр җыела. Гармунчы Фәйзулла Туишев Донбасс турындагы җырны сузып җибәрә. Шулвакыт алып баручы кинәт кенә: «Оркестр «Батыршин маршы»н башкара», – дип игълан итә...

Бөек Ватан сугышы

Геройны Мәскәүгә, Фрунзе исемендәге хәрби академиягә укырга җибәрәләр. Бөек Ватан сугышы аның өчен Белоруссиядә, уку йортын тәмамлаганнан соң стажировка үткәндә башлана. Ул хезмәт иткән часть камалышта кала. Аннан чыгу өчен Батыршин җитәкләгән отрядка, дошман тылы буйлап сугыша-сугыша, меңнәрчә чакрым юл үтәргә туры килә. Соңрак ул Сталинград янындагы сугышларда батальон командиры була, Белоруссияне азат итүдә катнаша. Кызыл Йолдыз ордены, II дәрәҗә Ватан сугышы ордены, Кызыл Байрак ордены һәм бик күп медальләр белән бүләкләнә. Сугыштан соң майор Батыршин, Казаннан гаиләсен алып, Мәскәүгә күченә. Яшь офицерлар – булачак чик сакчыларын үз тәҗрибәсенә өйрәтә.

Дөреслек яклы

1947 елны Гыйльфан Батыршинны, шаһит буларак, Токиога – халыкара хәрби трибунал процессына чакыралар. Ул анда, бары тик дөреслекне генә сөйләргә ант итеп, 1938 елда Хәсән күлендә булган вакыйгаларны бәян итә. Әмма аны провокацион сораулар белән күмеп ташлыйлар, японнар белән бәрелеш очраклы гына, куе томан аркасында килеп чыкты дип әйттермәкче булалар. Шулвакыт Япония короллы көчләре министрын яклаучы залга олы яшьтәге бер японны чакыра. Ул үзен, чик сакчысы идем, дип таныштыра. Гыйльфан кинәт бәрелеш вакытында үзләренә һөҗүм иткән бу кешене танып ала һәм судка болай дип мөрәҗәгать итә: «Мин бу кешене, чыннан да, Хәсән күле буенда күрдем. Әмма ул чик сакчысы түгел, ә жандармерия гаскәре офицеры иде. Гомерен саклап калуыбызны үтенде. Без шундый адымга барсак та, ул бүген, дөреслек яклы булырга ант биреп, ялган сөйли. Аның документлары да безнең кулда. Кызганыч, алып килергә уйламаганбыз», – дип сөйли. Шулвакыт совет прокуроры Танаки Рюкачиның хәрби билетын өстәлгә китереп куя. Хәтта шушы бер документ кына да Хәсән күле янындагы бәрелешнең чик сакчылары арасында очраклы гына килеп чыкмавын, ә жандармерия офицерлары тарафыннан алдан уйланылган провокация икәнен раслый.

1947 елның 11 декабрендә 33 яшьлек Батыршин утырган самолет Владивостокка килеп җитә алмый. Кинәт кенә суга төшеп китә дә бата. Очкычтагылар барысы да һәлак була. Әлеге фаҗиганең ни сәбәпле килеп чыгуы бүгенгә кадәр ачыкланмаган әле.

1970 нче еллар башында башкалабызның бер урамына Гыйльфан Батыршин исеме кушыла. Тарихи ватанында – Ямаширмә авылында аның истәлегенә һәйкәл куела, мәктәптәге Дан музеенда Геройга багышланган почмак ясала. Музей җитәкчесе Чулпан Галиәхмәтова: «Мәктәптә ремонт бару сәбәпле, әлегә барлык экспонатлар да җыеп куелган. Ачылгач та, музейны яңартырга уйлыйбыз. Тик, ни кызганыч, экспонатлар белән мактана алмыйбыз, фотографияләр генә бар. Кызлары Әлфиянең ире Рафаэль бер кайтып киткән иде. Әтиләренең әйберләрен шушы вакыйга уңаеннан Сахалинда ачылган музейга тапшырганнар булып чыкты. Белешә торгач, мин үзем дә Батыршиннар күршесендә яшәвемне ачыкладым. Кайчандыр аларның өйләрен күрше Урал авылы кешеләре сатып алган икән. Истәлекләрне барларга тырышабыз инде», – диде. Ни кызганыч, без беренче каһарманыбыз турында, чыннан да, бөтенләй белмибез кебек тоелды миңа. Күпме генә сораштырып карасам да, «Казанның Киров районындагы Батыршин урамы кем хөрмәтенә аталган?» дигән сорауга дөрес җавап бирүче табылмады...

СССР яшәгән чорда барлыгы 12777 кеше Советлар Союзы Герое исеменә лаек була. Шуларның 7998е – рус милләтеннән, 2021 украин, 299 белорус, 161 татар, 107 еврей, 96 казах, 90 грузин, 89 әрмән, 67 үзбәк, 63 мордва, 45 чуаш, 43 азәрбайҗан, 38 башкорт, 31 осетин, 18 мари, 16 төрекмән, 15 литвалы, 15 таҗик, 12 латыш, 12 кыргыз, 10 коми, 10 удмурт, 9 эстон, 8 карел, 8 калмык, 6 кабардин, 6 адыгей, 4 абхаз, 2 якут, 2 молдован, 1 тывалы. Бу исемлектә репрессияләнгән халыкларның вәкилләре юк.
Советлар Союзы Герое исеме 12618 кешегә – бер тапкыр, 154 кешегә – ике тапкыр, өч кешегә – өч тапкыр (Семен Буденный, Иван Кожедуб һәм Александр Покрышкин), 2 кешегә дүрт тапкыр (Леонид Брежнев һәм Георгий Жуков) бирелә.
Советлар Союзы Геройлары арасында балалар һәм яшүсмерләр дә бар: Леня Голиков (16 яшь), Марат Казей (14 яшь), Валя Котик (14 яшь), Зина Портнова (17 яшь).
Хатын-кызлар арасыннан иң беренче Советлар Союзы Герое – очучы Валентина Гризодубова.
Соңгы кеше булып бу мактаулы исемгә 1991 елның 24 декабрендә Леонид Солодков лаек була. Аңа бүләкне, СССР таркалып, 22 көн үткәч кенә тапшыралар. Ул шуңа күрә «Советлар Союзына хезмәт итәм» дигән сүзләр урынына «Рәхмәт» дип кенә әйтә ала.

ӨМЕТ ЯШӘТӘ

Буада яшәүче 48 яшьлек Әлфәт Хөсәенов әнә шулай ди. Матур гына тормыш иткәндә, бер-бер артлы туган кызларына сөенеп очып кына йөргәндә, ул кинәт аякларына баса алмый башлый. Башта аксый, аннан инде таяксыз йөреп булмый, соңыннан хәрәкәтләнү бөтенләй бетә. Күңеленә кыен, йөрәгенә авыр булса да, башка чарасы калмый: Әлфәт инвалид арбасына утыра. Шуңа да карамастан, бирешми. Киләчәккә зур хыял белән яши ул: кызларын кияүгә үз аягында бирәсе килә.

Без килгәндә, Әлфәтнең кайгылы чагы иде. Күптән түгел әнисен җирләгәннәр. Ашын уздырырга җыеналар иде. Әлфәт әтисен моннан 16 ел элек югалткан. Шөкер, дүрт туганы да исән-сау. Аларның һәркайсы энеләренең хәлен белеп тора икән. Тик ул гына берәүне дә борчырга теләми. Хатыныма да, якыннарыма да авырлык китерәсем килми, ди.

– Сорап алган чирем түгел дә бит! Баштарак кыен булса да, тора-бара авыруны кабул итеп, үземне кулда тотарга өйрәндем. Дөрес, кешедән кыенсыну, башкаларга күренергә теләмәү бар иде. Оялдым да мин. Йөгереп эшләп йөргән җиремнән аяксыз калу тормышымны икегә бүлде. Ничек тә яшәргә кирәк дидем үз-үземә, – дип сөйли Әлфәт. – Ул чагында миңа 41 яшь иде. Өченче кызыбыз туып күп тә үтмәде, мин авырый башладым. Табиблар да эшнең нидә икәнен әйтә алмадылар. Тикшеренеп йөри торгач, «рассеянный склероз» дигән диагноз куйдылар.

Әлфәт башта таякка таянып йөреп карый. Инде аяклары тыңламый башлагач та, бирешергә теләми ул. Диварга тотынып атламакчы була. Тик авыру үзенекен итә. Менә шул чакта хатыны Рәсимә, әнисе, бертуганнары ярдәм кулы суза. Алар аңа терәк була. Әлфәт аларга рәхмәт укый. Төп терәге – хатыны һәм кызлары: 17 яшьлек Әдилә белән 15 яшьлек Алинә. Быел мәктәпкә барырга

Илдар Мөхәммәтҗанов

җыенучы Ралинә дә, балалар бакчасына киткәндә, әтиләре күңелсезләнеп утырмасын өчен, үзенең йомшак уенчыкларын диванга утыртып китә икән. Янәсе, әтисенә дуслар булсын!

Кызлар турында сөйләшкәндә, Әлфәтнең күңеле тулды. Читкә карап, тиз генә күз яшен сөртте. Ә аннары елмаеп кына сүзен дәвам иттерде.

– Кызларым «әти» дип өзелеп тора. Алар минем өчен нишләргә белми. Игелекләрен инде күрәм дә. Әдилә белән Алинә, икесе бергә күтәреп, мунчага кертеп куялар. Әниләре юындырып чыгара. Үзем йөри алмый башлагач, хатынымны машина йөртергә укыттым. Хәзер ул шофер. Кая барасым килә, кая чакыралар – алып чыгалар да китәләр. Йөри алмыйм дип кимсенеп торганым юк. Инде хәзер кеше арасына да чыгарга оялмыйм. Урамнар кипшерүгә, коляскама утырам да рәхәтләнеп йөрим, – ди ул.

Әлфәт йөри алмый башлагач, нефть станциясендә бергә эшләгән дуслары коляска алып бирә. Аннары инде дәүләттән бирелергә тиешлеген белеп ала. Соңрак анысын да бирәләр. Ул кул белән йөртә торган була. Тик күп тә үтми, Әлфәтнең куллары да тыңламый башлый. Шуннан соң электр коляскасы алган. Хәзер шуның белән чаптырып кына йөри.

– Коляскага утыргач, өйнең бусагаларын үзгәртергә туры килде. Мин тиз генә йөрсен өчен, шулай көйләдек инде. Тик утырып, эш чыкмас, дидем. Вакытны буш уздырмас өчен, компьютерга өйрәндем. Аннары шәҗәрәләр төзи башладым, – ди ул. – Иң элек әти ягыннан туганнарымны барладым. Аннары әнинекен. Ике нәселгә 6500 кешене таптым. Әкренләп туган авылым Иске Суыксудагы кешеләрнең дә нәсел шәҗәрәсен төзедем. Аннары инде Яңа Суыксуныкын да ясадым. Барысы да электрон вариантта саклана. Аларны китап итеп булмый. Шәҗәрәләр озын алар. Үзебезнең бер як нәселнеке 3 метрга җитә.

Чит кешеләргә дә булышырга әзер ул. Нәсел шәҗәрәсен ясап бирүне сорап килсәләр, рәхәтләнеп эшлим, ди.

> Бик тә аякка басасым килә. Табиблар ышанмаса да, мин ышанам. Төшләремдә гел үзем йөрим мин. Димәк, Алла боерса, элеккеге чагыма кайтачакмын әле. Аллаһы Тәгаләнең кодрәте зур аның.

– Миңа бервакыт Казан хастаханәсендә ятарга туры килде. Ул чакта әле бераз йөри ала идем. Күрше бүлмәдә бер танышым ята. Ул йөри алмый иде. Мин аның янына кердем. Үземчә, тынычландырасым, өмет бирәсем килде. Ә ул борылды даятты. Әнә шунда мин аның рухы сынганны аңладым, – ди Әлфәт. – Аннары инде җылы сүзләр үземә кирәк булды. Мин көчле рухлы булырга сүз бирдем. Әле хәзер дә күңелне төшермим. Миннән дә авыр хәлдә ятучылар барын уйлап, шөкер итәм. Өметне өзмәскә кирәк. Башка берни кирәкми, шул гына җитә!

...Казанга кайтканчы, Әлфәтнең елмаюы озатып барды. Мин аңа сокландым. Көчле рухлы ир дип чыктым өеннән. Ә ул мине, аякка баскач, кунакка чакырам, дип озатып калды.

БЕР АВЫЛДА – ӨЧ МӘЕТ

Питрәч районының Ленино-Кокушкино авылы халкы бу көннәрдә күз яшьләрен түгә. Бергә уйнап үскән ике егет, ике кыз Казан эчендә аварияга очрый. Алар утырган машина башта юл кырыендагы тимергә бәрелә, аннан баганага килеп төртелә. Машина икегә аерыла. Рульдәге 19 яшьлек Ранэль белән 21 яшьлек Диана урында ук һәлак була. 19 яшьлек Даниил белән 17 яшьлек Камилланы хастаханәгә озаталар. Әмма, ни кызганыч, Даниилны коткара алмыйлар...

– Бөтен авыл елый. Балалар да, аларның әти-әниләре дә кызганыч. Шушы хәбәрне ишеткәннән бирле йөрәк әрни, – ди Ленино-Кокушкино авылында яшәүче Ләйлә Гайфуллина. – Рульдәге егет күрше малае иде. Әнисе Айгөл аны ялгызы гына үстерде. Алар Даниил белән бик якын дуслар иде. Балалар бакчасыннан бирле бергә. Гомерләре дә бер вакытта өзелде. Кызларның әниләре бертуган. Диана624 туй күлмәкләре кидереп җирләделәр. Әле ярый, Камилла исән калды. Әмма аның да бөтен сөяге сынып беткән, диләр.

Егетләр икесе дә Казанда укыган һәм буш вакытларында «Макдоналдс»та эшләгәннәр. Ял көнне эштән кайтышлары булган. Дус кызларын да кайтарып куярга уйлаганнар. Тик юллары гына кыска булган. Исән калган кыз, узган ел 9 нчы сыйныфны тәмамлап, шәһәргә киткән. Аңа быел 17 яшь тулган. Камилланың да хәле җиңел түгел.

– Бу хәбәрне ишеткән көнне ничек эшләгәнемне хәтерләмим дә, – ди авылдашлары, Кәрим Тинчурин театры актрисасы Гөлназ Нәүмәтова. – Дарулар белән генә тынычланып торам. Әти-әниләренә нинди зур хәсрәт. Баланы үстереп буй җиткергәч, салкын җир куенына сал инде... Айгөл өчен йөрәкләрем өзелә. Иреннән аерылгач, ул әти-әнисе белән генә яшәде. Баланы аякка бергәләп бастырдылар. Аның улының кешелекле, акыллы икәнен бөтен кеше сөйли. 18 яше тулгач, «права»га укыган. Таныклык алгач, әнисе машина да алып биргән. Балага начарлык теләмисең бит инде. Исән-сау йөрсен, дигәндер ул да. Тик күрәчәк үзенекен итә.

Ул Айгөлнең улын соңгы юлга озатырга кайта алмаса да, әти-әнисе аша авылдашларының хәлен белеп тора икән.

– Айгөл бик сабыр инде ул. Гомере буе балалар бакчасында эшләде. Бердәнбер баласын югалтуны авыр кичергәндер, беләм. Әмма ничек кенә юату сүзләре

vk.com

әйтсәң дә, аның хәлен аңлый алучы булмас. Бик зур хәсрәт инде бу. Баласын югалткан авылдашларыма сабырлык телим, – ди ул.

Гөлназ башка балаларның да әти-әниләрен белә. Даниил гаиләдә уртанчы малай була. Тырыш, уңган дип мактыйлар аны да.

– Даниил комада дигәч, исән калыр дигән өмет бар иде. Тик без теләгәнчә генә түгел бит, – ди Гөлназ. – Камилла минем күз алдымда үсте. Мин аның кечкенә чакларын да хәтерлим. Ул баланы тагын да катырак кызгандым. Фаҗига вакытында бары тик ул гына аңында булган. Барысын да күреп торган. Тән җәрәхәтләре төзәлер ул, әмма йөрәк ярасы үзен сиздерер инде. Аңа бигрәк авырдыр. Язмышларны узып булмый икән. Тәкъдиргә язылганны үтәбез.

«ВТ» редакциясе дә фаҗигадә балаларын югалткан әти-әниләрнең кайгыларын уртаклаша. Камиллага сәламәтлек тели.

Гөлгенә ШИҺАПОВА әзерләде

ИЛФАК ХАФИЗОВ:

«ЯҢАЛЫК ДИП, ҮЗЕБЕЗНЕ ЮГАЛТМАСАК ИДЕ»

Берәүләр роль дип чат ябышканда, ул, тулаем ача алмадым дип, баш тартырга, бертөрлелек башланса, гомумән, эштән китәргә мөмкин. Бәлкем шуңа да Тинчурин театры артисты Илфак ХАФИЗОВның рольләре ихластыр. Без аның белән театр тормышы, «рәхәт» һәм «авыр» рольләр, күңел халәте, хәзерге вазгыять турында сөйләштек.

:: Сәхнә ул – ...
– ...көн дә яңа язмыш!

:: Ләкин бит сәхнәдән китеп торган вакытларың да булды. Сәбәбе нидә иде?
– Китүем, бер караганда, кинәт булса, икенче яктан, соңгы елларда ул хакта уйлана идем инде. Ниндидер этәргеч кенә кирәк булгандыр. Ул елны мин театрдан башка дөнья белән таныша башлаган идем. Әйтик, Теләче районының 25 еллыгы бәйрәмендә үземне режиссер буларак сынадым. «Болгар радиосы» концертларына сценарийлар яздым, киноларда икенче режиссер, администратор буларак эшләп карадым. Ошый башлады. Чөнки анда киңлекләр башка. Ә тамашачы шул ук диярлек. Шуңа күрә ул вакыттагы баш режиссер белән аңлашылмаучанлык бер этәргеч кенә булгандыр. Ә бәлки шулай тиеш булгандыр. Ләкин үкенмим. Ул мине сәхнәне башка яктан аңларга өйрәтте. Әмма яраткан театрыма хыянәт итмәдем... Гел күзәтеп бардым һәм 3 елдан кире әйләнеп кайттым. Чөнки театр ул – башка дөнья!

:: Сәхнәдә остазың дип әйтерлек кешең бармы?
– Остазым бер: Заһидуллин Рәшит Муллагали улы. Ә калганнар – үрнәк.

:: Ир башың белән сәхнәдә уйнап йөрисең, дип әйткәннәре дә булгандыр әле.
– Булды. Әтием Илшат та артист булуымны башта кабул итмәде. Театрда ике-өч ел эшләгәч кенә күнде. Авылдагы абыйапалар, улың молодец, булдыра, дигәч кенә, фикере үзгәргәндер. Ачуланмаса да, канәгать түгел иде. Ул миңа: «Ир-ат бул, нык бул», – дип әйтә килде. Аның өчен ир-ат уйнап йөрергә тиеш түгел, эшләргә тиеш. Ә башкалар, сөйләнсә дә, аяк терәп каршы килмәде. Минем терәгем нык иде. Әнием миңа ышанды...

:: Кабил, Хөкемдар, Кәрим Тинчурин һәм башка бик күп рольләр башкарган актер син. Үзең рольләрне «тормышлар» дип атыйсың икән. Иң авыр «тормышлар»ның берсенә тукталыйк әле.
– Авыр, тетрәндергеч язмышлы образларны уйнау рәхәт. Анда казынасың, геройны аңларга тырышасың. Аның белән бергә бәргәләнәсең. Әйтик, «Сәйдәш. Йокысызлык» спектаклендә Кәрим Тинчурин роле тетрәндергеч иде. Ул «галәм»не мин ачып бетерә алмадым дип саныйм. Физик яктан да, күңел халәте, акыл белән дә кабул итү авыр иде. Аның кичергәннәрен күз алдына да китереп бетереп булмый. Шуңа күрә, шашмасам ярар иде дип, үземне тыярга туры килде.

Ә менә «Син бит – минем бергенәм» (авт. – Исламия Мәхмүтова) спектаклендәге Айнурның тормышы бик авыр, әмма аны уйнау әйтеп бетергесез рәхәтлек бирә. Анда бар да гади һәм аңлашыла. Бәлки кайвакыт артык катлауландырырга да кирәкмидер...

:: Танылу артистны бозамы? Үзеңә шундый «бозылу» яныймы?
– Кем ничек кабул итә бит... Шуны әйтә алам: танылу бик нык файда китерә. Әйтик, гади тормышта кешеләр белән аралашканда, башкача мөнәсәбәт. Артист бу, дип мактамасалар да, хөрмәтләре сизелә. Мин исә «тишек бер тиен» кебек гади булырга тырышам. Чөнки авыл малае, гадилек яратам. Кайчак артыграк мактый башласалар, уңайсызлыктан тизрәк сүзне башкага борам. Без бит барыбыз да бертигез. Барыбыз да – адәм балалары. Минемчә, кешене һөнәренә карап түгел, кылган гамәленә карап хөрмәт итәләр...

Мине бозармы дигәндә, бозмаса ярар иде, дигән теләктә калам. Берәү дә бозылуым әле дип бозылмыйдыр. Ялгыш борыны гына күтәрелеп китәдер. Әлбәттә, эш күплеге, вакыт җитмәү аркасында кайбер кешеләрнең «үзгәрдең әле син» дип әйткәннәрен ишеткәлим. Алар алдында гафу үтенәм. Мин бары җитешмим генә, зинһар, кичерсеннәр. Ә вакыт булганда, сөйләшер өчен мин һәрчак ачык. Әгәр ярдәмем кирәксә, бар эшемне ташлап чабарга да әзер.

:: Нинди рольгә алынмас идең?
– «Зәңгәр»не, хатыншаны уйнамас идем.

:: Тинчурин театры үзгәрештә. Үзең ул үзгәрешләргә өлгерәсеңме? Яңалыкны авыр кабул итә торган кешеме син, әллә җиңелме?
– Мин яңалык яклы!
Киләчәктә – якты!
Балкый анда өмет, хыяллар...
Тик аркада – җоннар,
Үрә торган алар.
Артта калган эздә –
Үлекләр...

Шушы шигыремнән бар да аңлашыладыр. Яңалык дип, үзебезне югалтмасак иде...

:: Элек тинчуринлыларны икегә бүленгән дип сөйлиләр иде. Ә хәзер хәлләр ничек?
– Директор – хуҗа, режиссер роль бирә. Ләкин минем өчен кыйбла күренми.

:: Иҗат эшенең кадере бармы?
– Бар. Без кешеләрнең күңеленә, аңына йогынты ясый алабыз. Яхшылыкка гына илтсәк иде. Үрнәкме ул, гыйбрәтме, мөһим түгел. Минемчә, иң мөһиме – тамашачыны яхшылыкка илтү.

:: Социаль челтәрләрдә тагын бер талантың ачылды: көнүзәк хәлләргә багышлап, шигырьләр язасың икән. Бу – күңел бушату алымымы?
– Чыннан да, бу – күңелемдә кайнаган фикерләрдән арыну ысулы. Ул уйлар, бәргәләнүләр корт кебек эчтән кимерә. Ә язып чыккач, җибәрә. Җиңел сулап куясың. Элек кешеләргә күрсәтми генә ноутбукка җыеп бара идем. Тик алай гына күңелне бимазалаган хистән котылып булмый икән. Бары кемгәдер әйткәч, кешеләр алдына чыгаргач кына бушанам.

:: Без бик үзенчәлекле чорда яшибез. Кешелек гыйбрәт алырмы икән бу хәлләрдән?
– Алганы ала, алмаганы – юк. Театрда «Без – 41 нче ел балалары» спектаклен уйныйбыз. Андагы вакыйгалар матур тел белән, шаяру аша язылса да, сүзләр астында авыр тормыш чагыла. Спектакль ахырында мин: «Авыр кырыс еллар үтелгән. Ничек үтә алганбыз, аңа каян көч килгән? Әйе, хәтерлим, безгә яшәргә, үз бурычыбызны үтәргә кирәк иде. Әйе, безгә ЯШӘРГӘ кирәк иде!» – дигән сүзләр әйтәм. Бүгенге вазгыятьтә дә безгә ЯШӘРГӘ кирәк. Ә ничек яшәргә дисәгез, анысын кем ничек булдыра ала инде.

:: Мөмкинлек булса, тормышыңда нәрсәне үзгәртер идең?
– Үткәнгә кайтып булса, тизлекне. Хәзерге акылым булса, буш вакытымны тулыландырып бетерер идем. Ә хәзерге көндә мин бәхетле!

Әңгәмәдәш – Гөлинә ГЫЙМАДОВА

Блиц-сораштыру

– Илфак, Алла боерса, өч тапкыр бабай буласың бар бит әле. Булачак киявләреңә нинди таләпләр куячаксың?
– Кызларымны яратсыннар, бәхетле итсеннәр. Калганы үзләре теләгәнчә...
– Өстәл китабың нинди?
– Кәефкә карап... Аерым бер китабым юк.
– Холкыңны өч сүз белән тасвирлыйк әле.
– Үзсүзле, җаваплы, юләр-тәвәккәл.

ИЛФАК ТУРЫНДА КЫЗЫКЛЫ ФАКТЛАР

- ✓ Рус авылында туганлыктан, теле «мама» дип ачылган.
- ✓ Беренче сыйныфта шигырь язып, Кыш бабайга сөйләп, бүләк алган.
- ✓ Көрәш буенча 3 нче разрядлы спортчы.
- ✓ Театр артисты булу карарын 1 апрель, шаяру көнендә кабул иткән.
- ✓ Казан театр училищесын беренче яртыеллыктан соң ташлап кайтып китәргә теләгән. Бары тик әнисеннән оялып кына, каникулдан соң укырга килгән.
- ✓ 3 нче курсны тәмамлагач, җәй көне печән алып кайтканда трактор арбасы астында калып, үлем белән күзгә-күз очрашкан.
- ✓ Хикәяләр, шигырьләр, җырлар авторы.

Кайчан карама тәрәзә янында утырган Маһинурга авыл халкы да, анда кайтып йөргәннәр дә күнегеп беткән инде. Яңа төшкән киленнәр генә озак ияләшә, кабул итә алмый азапланалар, чөнки ул аларны күзәтә кебек. Тик ялгыша алар, ялгыша, Маһинурда алар кайгысы юк. Күзләре – заманында менә дигән итеп салынган йортның көннән-көн җиргә иңгән тәрәзәләре аша, каршы йортта яшәгән Таһирәттәйләрнең ихатасында. Авыл урамын күтәртеп, таш юл салгач, болай да үзенә йомарлана барган йорт әйтерсең тагын да бәләкәйләнеп калды. Тәрәзә төбе саклаучысы да аңардан калышмый, әкрен генә бәләкәйләнә, суна. Кайчандыр тулы гәүдәле булган, күкрәкләре берсеннән-берсе матур күлмәкләренә сыймаган, сөеп һәм сөелеп туймаган Маһинур да, беркөн килеп, аның белән бергә югалыр, онытылыр. Адәм баласы бу фани дөньяга мәңгелеккә килмәгән бит.

Маһинур, каршысында яткан таушалып-майланып беткән әллә ничә еллык дәфтәрне ачып, нидер язарга тотынды. Хәер, язу дисәң, хәтерең калыр – үзе дә дәш чит кеше түгел, колхоз байлыгының чиге юк аның», – дигән уйларының эчкә җылылык бирүе дә бик килеште, моңа булышты бугай.

Һәр эшне җиренә җиткереп эшләргә күнеккән Таһирә беренче көннән үк тәртип урнаштырырга керешә. Бианасының йорт-ихатага, балаларга күз-колак булып яшәве дә бик зур ярдәм, терәк булды. Бераздан эшләр җайга салынып, үзе дә эшнең асылына төшенә башлады. Урып-җыю эшләре башланганда, бөтен җирдә тәртип булдырылып, аткарыласы тиешле дәрәҗәдә аткарылды. «Быел йорт белән булышмабыз, әнисе, ныклап кереп кит әле эшеңә, аннан карарбыз, искесе дә торырлык», – дип, Сабир яз көне үк әйтеп куйса да, бианасы: «Осталарга үзем ашарга әзерләрмен, ниятләгән эшне туктатмыйк», – дип каршы төшеп матaшты. Ләкин тагын бергәләп утырып сөйләшкәч, быелга салмаска дигән уртак фикергә килделәр.

Ул елны уңыш җыеп та, урнаштырып та бетермәслек күп булды. Ел саен механизатор Сабир өчен генә алынган ашлык янына быел Таһирә өлеше дә өстәлде. Колхоз җитәкчелеге ... башсыз икән! Күрәләтә торып, колхозны талаталар.

– Бернәрсә аңламыйм, нәрсә сөйлисең син, ахирәт?

– Әнә ирең ачыкласын, ул бит – колхозның халык күзәтчесе. Карале, әйкәем, башы керсә, аягы кермәгән, аягы керсә, башы юк дигәндәй, бер ел эчендә шулкадәр йорт җиткереп чык әле. Менә синең кулыңнан килер идеме?

– Бә-әй, Таһирә амбарга эшкә чыкканчы ук, буралап, кирәк-яракларын әзерләп куйганнар иде түгелме соң?

– И-и, һич сине алай ук прастуй башсың дип уйламый идем. Булгач та булырсың икән! Бураларына тагын шулкадәрлесен китереп өстәделәр ич! Әллә бушка берәрсе китереп биргәнме? Тотырган ди! Амбардагы әйбернең аның чуты-мазары юк, теләгәнен чыгар да сат! Ашлык белән дә әллә нәрсәләр майтарып була.

– Шулкадәр чәпчемә әле, гүпчим анда эшләп караган кеше кебек сөйлисең. Мин, мәсәлән, боларның берсен дә белмим, башыма да кертеп караганым юк.

ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА

СӨЕП, СӨЕЛЕП ЯШИСЕМ КИЛӘ!

(ХИКӘЯ)

танымый нәрсә язганын. Шулай да, авыз эченнән нидер мыгырдана-мыгырдана сызгалавын дәвам итә. Ә күзләре – ихатасына ниндидер йомыш белән чыккан Таһирәттәйдә...

***

«Таһирә колхоз амбарына мөдир итеп куелган» дигән хәбәрне халык төрлечә кабул итте. «Яхшы булган, аңардан да кулай кеше юк», – дигәннәр дә, «Тапканнар!» – дип тел шартлатучылар да булды. Арада берсеннән-берсе кечкенә дүрт балалы Таһирәне җәлләүчеләр дә табылды. Чөнки йорт салырга дип, көздән бура ясатып, такталарын да ярдырып куйганнар иде. «Өй салуның ние бар – мүклисе дә чутлыйсы» диючеләр арасында үзе өй җиткереп караган кеше юктыр. Булса, бу сүзне әйтмәс. Җиңел эшләрдән түгел ул өй салу. Җитмәсә, мөдирнең мәшәкатьле, хәтта ирләр өчен дә авыр хезмәт икәнен искә алсаң, я тегесен, я монысын сайларга туры киләчәк. Элекке эше, беренчедән, «сәгатьле», ягъни вакытында килеп-кайтып йөри торган булса, икенчедән, күнегелгән иде. Ә монда барысын да өр-яңадан башларга кирәк. Сабир каршы килсә, әлбәттә, Таһирә ризалашмас та иде. Ире тарафыннан хуплау алу аның ышанычын нығытты һәм ул ризалыгын бирде.

Бу хәбәргә иң көенгән кеше килендәше Зарифа булгандыр. Чөнки үзе күптәннән шушы урынны «сагалап» тора иде. «Пошмас Галине төшерәләр икән!» дигән хәбәрне ишетү белән, ферма мөдире булып эшләгән ире Мәҗитнең колак итен әз чәйнәмәде. Әлбәттә, анысы хатынының үтенече белән колхоз рәисенә дә керде. Тик хуҗа идарәгә Зарифаның кандидатурасын чыгармады. Мәҗитнең район күләмендә алдынгы ферма мөдире, ихтирамга лаек кеше булуы да бу эштә ярдәм итмәде. Амбарга мөдир итеп «агроном» белгечлеге белән техникум тәмамлаган, авыл советында сәркатип булып эшләгән Таһирә тәгаенләнде. «Җүнсез! Кулыңнан берни килми синең!» – дип, берничә көн чәпчеп йөргәннән соң, Зарифа тынычлангандай итте. «Ярый, акмаса да тамып торыр, килентәлгәч, ышанмыйчарак та тордылар. Фәридә апаның, үзенчә, олыларча, саласы йорт турында уйлап: «Бирәм дигән колына чыгарып куяр юлына!» – дип, балалары өчен куанычының чиге булмады. Хуҗалыктан арткан ашлыкны сатып җибәрү җаен да таптылар. Быелгы урып-җыю чоры өчен алынган хезмәт хакларын электән туплаганнары янына китереп кушкач, өйне алты почмаклы итеп салырга булдылар. Ә язын, чәчү эшләре тәмамлану белән, йортка тотындылар.

Сабир белән Таһирәнең олы йорт салып чыгуларына кызышып та, көнләшеп тә карадылар. «Әйе, колхоз байлыгы белән без дә шундый олы итеп тә, җиңел генә дә салыр идек», – дип кычкырып әйтмәсәләр дә, эчтән шулай уйлаучылар булмады түгел. Зарифаның килендәше мөдир булып эшли башлаганнан бирле яна башлаган йөрәгенә ут капты. Җитмәсә, ахирәте Хәдичәнең терәлеп торган күршеләре! Килгән саен, күзләр теләсә-теләмәсә дә, патша сарае кебек кукыраеп торган йортка төшә дә: «Верандакайлары да, ичмасам, башкаларныкы кебек кечкенә түгел, буйдан-буйга!» – дип, көнләшүдән шартлардай була.

Әле бүген дә: «Сабирның хуҗалык эшләренә кулы ятып тора, минеке әйтерсең башка атадан туган, фермадан башка бернәрсә белми. Куна ятып эшләр иде, ата коммунист!» – дип, бусагадан исәнләшергә дә онытып, тиргәнә-тиргәнә килеп керде ул ахирәтләренә. Иренең кышын ат чанасына, җәен арбасына «ияреп» кайткан капчык-капчык мал азыклары турында, әлбәттә, ул дәшмәде. Куе кызыл күлмәгеннән дә кызылрак булып бүртенгән Зарифаны хуҗабикә тынычландырырга тырышса да, файдасы булмады. Күзләреннән үзенә генә хас зәһәрлек бөркелгән хатын эчендәгесенең бер генә бөртеген дә калдырмыйча, чыгарып салырга ашыкты. Гүя шулай эшләмәсә, хәзер дөнья бетәр дә, үзенең бурычын үтәмәгән килеш китеп барыр кебек тоелды.

– Таһирәне әйтәм әле, шулкадәр оятсыз дип уйламаган идем. Хуҗалар да

– Әнә шул берсенең дә башына кереп карамаганга, таратталар да инде колхоз малын. Өч кенә ел эшләп калган Пошмас Гали тиклем Пошмас Гали череп баеды бит – бөтен йорт-ихатасын яңартты, матай сатып алдылар. Кыскасы... моны болай гына калдырырга кирәкми, ахирәт! Күрәләтә торып, колхозны талатабызмыни? Чарасын күрик.

Хәдичә, нишләргә белмәгәндәй, аксыл көрән яулыгын чишеп, яңадан маңгаена кысыбрак бәйләп куйды да, газ плитәсен кабызып, чәй куеп җибәрде.

– Куй әле, Зарифа, юк белән булышмыйк, белми эшләгән гөнаһларыбыз өчен дә җавап бирәсебез бар әле...

Кайчандыр, укытучылар җитешмәгән елларда, җиде сыйныф белеме белән ике ел башлангычларны укытып йөргән Зарифа үзенә ут төрткән кебек, баягыдан да ныграк кабынып китте.

– Тәүбә-тәүбә! Ирең коммунист була торып, әллә Аллаһка ышанасыңмы, язмаганны?!

– Ышанам дип, дәү әниләр, инәйләрдән ишеткәнне әйтәм инде.

– Кит-кит! Юкны сөйләп торма, берәрсе ишетеп, жалу-мазар яза күрмәсен тагын! Әнә бер елны күрше авылдагы мәктәп директорын өйләрендә Коръән укытканы өчен эшеннән алганнар. «Үзем өйдә юк идем, олы яшьтәге инәй укыткан», – дип аңлатып караган да, кичермәгәннәр, белдеңме?

– Аллаһ сакласын!

– Кара, һаман телеңдә шул бер сүз! Ничек искә алмый йөргәнмен сине моңа кадәр, ә?! Ярар, мөшкәдә икенче әйбер әле, шул турыда сөйләшик. Әле менә ашлык тарата торган вакыт, ихаталарын күзәтү астына алырга кирәк булыр.

Чәй ясый башлаган Хәдичә, бу сүзләрдән соң, чак кына кулындагы чәйнеген төшереп җибәрмәде.

– Ничек күзәтү астына? Милиция булдыңмы әллә?

– Милициягә эш булсын өчен, башта үзебезгә әзме-күпме кыймылдарга кирәк!

Дәвамы бар >

Шигърият

Эльмира ШӘРИФУЛЛИНА

КАРГА БОТКАСЫ

Дәгъвалашып язгы ташу киткәч,
Язгы кояш җылы нурын сипкәч,
Узу белән апрель уртасы,
Пешә иде карга боткасы.

Җыеп безне – ыбыр-чыбырны,
Авылның иң өлкән карчыгы
Китәр иде...
Безне көтеп тора
Кыңгыр түбәтәйле таучыгы.

Табыннар мул хәзер –
Икмәк кенә
Түгел икән яшәү тоткасы.
Тик онытылмый түбәтәйле шул тау,
Шунда пешкән карга боткасы.

Ботка пешкәч, җыелышып,
Түбәтәй тау
Итәгенә килеп утыргач,
Күңелләрне кояш нуры белән,
Яшәү яме белән тутыргач,
Елмаер да иде Нурлый әби,
Сыйпап яңа шыткан үләнне,
Әйтер иде:
«Дошманыңа хәтта
Күрсәтмәсен безнең күргәнне!»

Ул чагында бала булганбыз шул,
Кызык булган безгә галәмәт...
Нурлый әби әйткән нурлы сүзләр –
Әманәт лә булган, әманәт.

Әманәтләр әйтер өчен генә
Пешергәндер, бәлки, ул аны.
Икмәк кискән саен хәтерлимен
Онытылып барган йоланы.

...Тормышлар мул хәзер,
Табыннар мул, –
Ә нәрсә соң яшәү тоткасы?
Каян гына искә төштең әле,
Онытылган карга боткасы?!

ХӘЕРЛЕ НИГЕЗ

Өй алганчы, күрше сайла,
Хәерле нигез булсын.
Өегездә һәр бирмеш көн
Кояш нурына чумсын!

Иманлы, имин нигездә
Ипле ул-кызлар тусын.
Һәрберсе нәселен саклар
Ныклы нигезен корсын!

Йортыгызга хәләл дәүләт,
Хөрмәт, мәрхәмәт тулсын.
Ата-анагыз түрдә булсын,
Тынычлап дога кылсын!

Хәерле нигезләр булсын,
Һәр нигезгә кот кунсын.
Өй түйлары бәхет белән
Шатлыктан гөрләп торсын!

КАЗ ӨМӘСЕ

Каурый чәчәм су юлына,
Ишле булсын казыгыз.
Өмәләрдә эш күрсәтеп,
Ярлар табып калыгыз.

Каз мамыгы яшь киленгә –
Түшәк, ястык, юрганга...
Дәртләнерсең, мамыктай кул
Иңнәреңә «кунганда».

Юл аягы – каз коймагы,
Сыйлансаң – суык тимәс.
Каз йолка белмәгән кызны
Егет солтаны сөймәс.

Бии-уйный сылу кызлар,
Чыңлый чулпы, төймәсе.
Борынгыдан килгән йола –
Татарның каз өмәсе.

Язучы фикере

Боз озату

Боз китүдән дә күңеллерәк күренеш юк иде бугай ул элек. Без, урамның бот буе малайлары, аны беренче булып каршылый торган идек. Бары тик яз вакытында гына була торган «пугач» дип аталган корал да хуттә иде әле ул чакларда.

Пугач ясамаган малай ул чын ир-егет түгел инде, синең кемлегеңне шул билгеләп. Кайвакыт аны велосипед «эспице»ннән ясый идек, монысы – узгынны нәрсә генә инде. Ә чын пугач ул трактор-комбайнның җиз торбасыннан ясала. Элек МТМ дип аталган нәрсә янында запчастьтан да күбрәк нәрсә юк иде бит. Менә шуннан табып аласың. Анда булмаса, эшләп торган берәр трактор я комбайнныкын каерып алып китәсең. Аны кисеп алу өчен тимер пычкысы әзерләп куясың, һич югы өч кырлы игәү белән маташтырасың. Шул торбаны этләй балыгы кадәр генә итеп кисәсең дә бер башын чүкеп бөклисең, торба эченә кургаш тутырасың. Шуннан сиксәнле кадакны кәкрәйтеп, бер башын кадакка, бер башын торбага эләктереп, җилем белән тарттырып куясың. Торба эченә күкерт тутырасың да, кадакны торбадан чыгарыбрак куеп, җилем белән тарттырып җибәрәсең. Бах-х! И, ул шартлау тавышларының матурлыгы! Ныграк шартлаган саен, ныграк бәхетле буласың. Боз киткәндә, елга буенда пугач тавышлары туктаусыз ишетелеп тора. Салют инде бу шундый. Аны кызлар арасында шартлату тагы да күңеллерәк. Алар, куркышып, чыр-чу килә. Алар курыккан саен, үзеңне батыррак итеп тоясың. И, кызлар чыркылдашуыннан да рәхәтрәк нәрсә бармы соң инде бот буе малайлар өчен!

Пугач ясаулар да, бозда йөзүләр дә шул кызларны чыркылдату өчен генә иде бугай инде. «Кызлар» дип аталса да, арасында синең күзең төшебрәк йөргән иң кадерлесе дә бар бит әле. Шуның янынарак елышырга тырышасың, шуны куркытудан тәм табасың. Малай чак мәхәббәтенең үз теле бит инде ул. Шуның игътибарын яуларга тырышып, елга уртасындарак йөзгән бозга сикерәсең. Уңышлырак килеп чыкса, якты елмаю белән аңа текәләсең. Ул бик игътибар бирмәгән була инде. Гел уңышлы да булмый әле ул, син сикергән боз я бәпчеп шуып китә, я өсте аска килә. Син муеныңнан суга чумасың, ә теге кыз сөенә. Кычкырып көлә, аның синнән көлүе дә рәхәт. Синнән көлгән кешеләр арасында аның булуы рәхәт. Берәр дустың киртә суза, син шуңа ябышып чыгасың да бер як читтәрәк янып торган учак янына барып, киемнәреңне сыгара тотынасың.

Иң кызыгы кечкенә якта була бугай инде аның. Трактор арбасының тәгәрмәчен алып, тау башына менәсең. Шуннан моңа солярка сибеп, ут төртәсең. Яхшы гына итеп бер киткәч, тау түбәсеннән төшереп җибәрәсең. Яна-яна матур булып төшә ул. Төшә дә, Сөн буена җиткәч, ярдан сикереп, боз өстенә килеп кунаклый. Аның артыннан бер кәтү булып, дәртле авазлар чыгара-чыгара, малайлар да йөгерә инде. Кайчагында тәгәрәп тә каласың, тик бу дәртне сүндерми, сикереп торасың да тагын дәвам итәсең. Рәхәт инде шундый.

Аның иң рәхәте теге тәгәрмәч боз өстенә уңышлы яткан очракта инде. И, әллә нинди могҗизаларга тиң булып тоела ул. Сөн Агыйделгә коя бит инде, Агыйдел – диңгезгә, диңгез – космоска. Нәкъ менә шулай тоела иде ул чагында. Синең таудан тәгәрәтеп җибәргән ялкынлы тәгәрмәчең космоска кадәр менеп җитәр дә анда бер йолдыз булып янып торыр кебек иде. Без моның нәкъ шулай икәнен төгәл белә идек. Елга буена төшкән өлкәнрәк кешеләр генә ул берни дә аңлап бетерми, хәтта үзалдына сөйләшкән чакларында да бер-берсеннән сорап куярлар иде:

– Бу елгалар кая ага икән?

Әле менә Сөн буеннан кайтып киләм. Авыл урамнары да, елга буйлары да элекке шикелле шау-гөр килеп тормый инде. Минем кебек үткәннәрен эзләп чыккан берничә кешедән башка җан иясе юк. Малайлар юк. Кызлар юк. Яшьләр дә юк. Сөн бозлары да элекке шикелле кукыраеп, үзләренең әллә кемлеген аңлап акмый. Алар ашык-пошык җыенып, илләреннән качып китүче мөһаҗирләрне хәтерләтә. Шулай булырга тиештер дә инде ул. Алар хәзер космоска акмый бит. Алар да хәзер нибары Җирнеке генә.

Тик минем күңелдә – сагыш. Үткәннәрнең бүгенгедән, бүгенгенең киләчәктән әйбәтрәк икәнен аңлаудан да авыррак хәл юк. Моңсу гына адымнар белән елга буеннан авылга кайтып киләм.

Бу дөньялар кая бара икән…

Марат КӘБИРОВ



Рәис Габдулла

8 апрель санында чыккан сканвордның җаваплары
Горизонталь буенча: хөрмәт, шәүвәл, көрән, Күги, ерак, Отс, Маша, аңкау, нано, гимн, лек, салями, аек, өрә, нам, Бабич, руда, Рауза, Лена.
Вертикаль буенча: Сөн, өләшү, Антара, Гоша, Лем, Мавритания, бүре, төлке, Лима, өрәңге, баул, Ра, Кикабидзе, Әкрам, чуан, унике.

СТРОИТЕЛЬНАЯ БРИГАДА
Выполним все виды строительных работ с нашим материалом

Строим дома, веранды, душ, хозблоки, беседки, бани, заборы, дорожки, красим дома, кладем печи, кафельную плитку. Подъем дач, ремонт крыш, заливка фундамента. Обшивка сайдингом, внутренние работы, делаем демонтажи.
тел.: 8 917 292 71 65
Пенсионерам – скидка!
Реклама

БРИГАДА
СТРОИТЕЛЕЙ ВЫПОЛНИТ ВСЕ ВИДЫ РАБОТ

Телефон: **89600509692**
Реклама

КАРНИКА һәм КАРПАТКА
токымлы бал кортлары семьясын сатам.
4 рамкалы, 2-3 кәрәзе – личинкалы,
1 кәрәзе – бал икмәге белән.
+7 96 55 99 88 67,
+7 96 25 61 60 93
Пчелопакет Карника и Карпатка комплектация по 4 рамки 2-3 расплодом + 1 медаперговая
Реклама

Баш мөхәррир –
САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Индекс П2435
Тираж – 16091 данә

Газетага сертификат бирелде
Заказ 253

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ
420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.
www.vatantat.ru
info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru
89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР
222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-67 – баш мөхәрририрнең беренче урынбасары
222-09-73, 222-09-69, 222-09-65 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы, фән һәм мәгариф
222-09-67 – дин, сәламәтлек
222-09-64 – әдәбият, сайт
222-09-66 – сәясәт, тәрҗемә, оператор, хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш. Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+